# ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№ 7*
*июль*
*2015*
*(I өлеш)*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘСМИ БАСМАСЫ
КАЗАН
2015

ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ:
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы

Формат 60x84 1/16. Тираж 32 экз.

© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, 2015

Эчтәлек

# I

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

666. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 116 статьясына үзгәрешләр кертү турында» *Татарстан Республикасы Законы* ....... 6

667. «Татарстан Республикасында гражданнарның эконом классслы торак сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....... 9

668. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү һәм «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законындагы 2 статьяның үз көчен югалтуын тану хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....... 11

669. «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....... 14

670. «Татарстан Республикасы дәүләт тормышындагы һәм җирле әһәмияттәге аеруча мөһим мәсьәләләр буенча халык фикер алышуы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....... 16

671. «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....... 17

672. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына

һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* .................................... 19

673. «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* .................................... 20

674. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* .................................... 34

675. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 24 статьясына үзгәреш кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ............. 54

676. «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 16 һәм 28 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..... 55

677. «Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына үзгәреш кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ................................ 56

678. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 10 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ............................................ 57

679. «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ................................ 59

680. «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ...............................367

681. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына җирлекләрнең региональ финанс ярдәме фондыннан



шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен тапшыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..............................382

682. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ............397

683. «Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....402

684. «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ............................................404

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 666. Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 116 статьясына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 116 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Балигъ булган яшьтәге ир-ат йә хатын-кыз уллыкка алучылар булырга мөмкин, моңа түбәндәгеләр керми:

1) суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылган затлар;

2) суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылган ир йә хатын;

3) суд тарафыннан ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән яисә ата-ана хокуклары чикләнгән затлар;

4) закон белән йөкләнгән үз вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгән өчен опекун (попечитель) вазыйфаларыннан читләштерелгән затлар;

5) элек уллыкка алганнар, әгәр уллыкка алу алар гаебе аркасында суд тарафыннан юкка чыгарылган булса;

6) сәламәтлек торышы буенча баланы уллыкка ала алмый торган затлар. Затның баланы уллыкка алу, аны опекага яисә попечительлеккә алу, бала алучы гаиләгә яисә патронат гаиләгә алу мөмкинлеген юкка чыгара торган авырулар исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны уллыкка алырга теләгән затларны медицина тикшерүе, медицина таныклавы гражданнарга түләүсез



медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасы кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтләр биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә уздырыла;

7) уллыкка алуны билгеләү вакытына уллыкка алынучы баланы тәэмин итәрлек, Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләмендәге кереме булмаган затлар;

8) даими яшәү урыны булмаган затлар;

9) әлеге өлешнең 10 пунктында каралган очраклардан тыш, шәхеснең җенси кагылгысызлыгына һәм җенси ирегенә каршы җинаятьләр өчен, шулай ук шәхеснең гомеренә һәм сәламәтлегенә каршы, ирегенә, намусына һәм абруена каршы (психиатрия ярдәмен стационар шартларында күрсәтә торган медицина оешмасына законсыз урнаштырудан һәм яла ягудан тыш), гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга каршы, халыкның сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлаклылыкка каршы, иҗтимагый иминлеккә каршы җинаятьләр өчен хәзерге вакытта яисә элегрәк хөкем ителгән, җинаять эзәрлекләвенә хәзерге вакытта яисә элегрәк дучар булган затлар (җинаять эзәрлекләве реабилитацияләү нигезләре буенча туктатылган затлардан тыш);

10) әлеге өлешнең 9 пунктында күрсәтелгән затлар арасыннан булган, шәхеснең гомеренә һәм сәламәтлегенә каршы, ирегенә, намусына һәм абруена каршы (психиатрия ярдәмен стационар шартларында күрсәтә торган медицина оешмасына законсыз урнаштырудан һәм яла ягудан тыш), гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга каршы, халыкның сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлаклылыкка каршы, иҗтимагый иминлеккә каршы авыр яисә аеруча авыр җинаятьләргә караган җинаятьләр өчен хөкем ителгән йә җинаять эзәрлекләвенә дучар булган затлар, мондый затлар суд тарафыннан уллыкка алына торган баланың гомеренә, сәламәтлегенә һәм намусына куркынычлы дип танылган очракта. Суд, баланың уллыкка мондый зат тарафыннан алынуы турында карар кабул иткәндә, уллыкка алына торган баланың тулы физик, психик, рухи һәм әхлакый үсешен баланың гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч янамыйча тәэмин итү мөмкинлеген билгеләү максатларында, затны җинаять эзәрлекләвенә дучар иткән гамәлнең шартларын, гамәл кылган вакыттан соң узган срокны, гаеп рәвешен, шәхесне характерлый торган шартларны, шул исәптән мондый затның гамәл кылганнан соңгы үз-үзен тотышын һәм башка шартларны исәпкә ала;

11) әлеге өлешнең 9 пунктында күрсәтелгән җинаятьләргә карамаган авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өчен хөкем ителгән затлар;

12) әлеге статьяның 6 — 10 өлешләрендә билгеләнгән тәртиптә әзерлек узмаган затлар (баланың якын туганнарыннан, шулай ук уллыкка алучы яисә элек уллыкка алган булган һәм үзләренә карата уллыкка алу юкка чыгарылмаган затлардан һәм балаларның опекуннары (попечительләре) булып торучы яисә булган һәм үзләренә йөкләнгән вазыйфаларын үтәүдән читләштерелмәгән затлардан тыш);

13) бер үк җенестәге затлар арасында төзелгән берлектә торучы затлар, ул мондый өйләнешү рөхсәт ителгән дәүләт законнары нигезендә өйләнешү дип танылган һәм теркәлгән булса, шулай ук күрсәтелгән дәүләт гражданнары булып торучы һәм өйләнешмәгән затлар.»;

2) 2 һәм 3 өлешләрдә «11» санын «12» санына алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 1 июле
№ 43-ТРЗ



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 667. «Татарстан Республикасында гражданнарның эконом классды торак сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның эконом класслы торак сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 28 декабрендәге 95-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 3; 2015, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1 статья. **Гомуми нигезләмәләр**

Әлеге Закон «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба — Федераль закон) нигезендә Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү федераль фондының (алга таба — Фонд) эконом класслы торак төзү өчен, кысаларында шул исәптән эконом класслы торак төзү күздә тотыла торган территорияне комплекслы үзләштерү өчен түләүсез файдалануга яисә арендага (алга таба — эконом класслы торак төзү өчен түләүсез файдалану яисә аренда), шулай ук эконом класслы торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү өчен, кысаларында шул исәптән эконом класслы торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү һәм башка торак төзелеше күздә тотыла торган территорияне комплекслы үзләштерү өчен арендага (алга таба — эконом класслы торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү өчен аренда) тапшырылган җир кишәрлекләрендә төзелгән яисә төзелеп килүче, эконом класслы торакка кертү шартларына туры килә торган күпфатирлы йортларда һәм (яисә) блоклы төзелә торган торак

йортларда торак урыннар, индивидуаль торак йортлар (алга таба – эконом класслы торак) сатып алу хокукына ия гражданнар исемлекләрен төзү кагыйдәләрен һәм күрсәтелгән гражданнарны Фондның эконом класслы торак төзү өчен түләүсез файдалануга яисә арендага, шулай ук эконом класслы торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү өчен арендага тапшырылган җир кишәрлекләрендә төзелгән яисә төзелеп килүче эконом класслы торак сатып алу хокукына ия гражданнар исемлекләренә (алга таба – исемлек) кертү тәртибен, аерым алганда, чиратын билгели һәм «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 21 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнарның эконом класслы торак сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле аерым мәсьәләләрне җайга сала.»;

2) 2 статьяның 2 өлешендәге 5 пунктында «вакытлыча» сүзен төшереп калдырырга;

3) 6 статьяның 1 – 3 һәм 6 өлешләрендә «вакытлыча» сүзен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 1 июле
№ 44-ТРЗ



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 668. Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү һәм «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законындагы 2 статьяның үз көчен югалтуын тану хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 1999, № 8 (I өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 25 статьяда:
а) 3 пунктта:
2 пунктчада «чүпләнүдән» сүзен «пычранудан» сүзенә алмаштырырга;
3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3) авыл хуҗалыгының уңдырышлы җирләрен агачлар һәм куаклар, чүп үләннәре басып китүдән яклау, шулай ук үсемлекләрне һәм үсемлектән ясалган продукцияне зарарлы организмнардан (билгеле бер шартларда агачларга, куакларга һәм башка үсемлекләргә зарар салырга сәләтле үсемлекләрдән яисә хайваннардан, авыру китереп чыгаручы организмнардан) яклау;»;
4 пунктчада «чүпләнүеннән» сүзен «пычрануыннан» сүзенә алмаштырырга;
6 пунктчада «үз вакытында хуҗалык әйләнешенә кертү» сүзләрен «җирләрне үз вакытында әйләнешкә кертү» сүзләренә алмаштырырга;

б) 6 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Кеше сәламәтлеген һәм әйләнә-тирә мохитне саклау максатларында туфракның торышын бәяләү өчен Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан зарарлы матдәләрнең, зарарлы микроорганизмнарның һәм җирне пычрата торган башка биологик матдәләрнең рөхсәт ителә торган иң чик концентрацияләре нормативлары билгеләнә.»;

2) түбәндәге эчтәлекле $33^2$ статья өстәргә:

«$33^2$ статья. **Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен социаль файдаланудагы наем йортлары төзү һәм алардан файдалану максатларында территорияне үзләштерү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга бирү**

Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләре социаль файдаланудагы наем йортлары төзү һәм алардан файдалану максатларында территорияне үзләштерү өчен Татарстан Республикасы яисә муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешмаларга социаль файдаланудагы наем йортлары төзү һәм алардан файдалану максатларында территорияне үзләштерү өчен түбәндәге очракларда торглар үткәрелмичә биш елга кадәр вакытка арендага бирелә:

1) коммерциягә карамаган оешма социаль файдаланудагы наем йортлары төзү һәм алардан файдалану максатларында территорияне үзләштерү буенча дәүләт яисә муниципаль программаларда катнашса;

2) социаль файдаланудагы наем йорты төзү һәм аннан файдалану максатларында территорияне үзләштерү турында билгеле бер җир кишәрлегенә карата шартнамә төзү хокукына аукционнар кимендә ике мәртәбә булмаган дип танылса һәм аукционда катнашуга гариза биргән бердәнбер зат белән, аукционда бердәнбер катнашучы дип танылган гариза бирүче белән яисә аукционда катнашкан бердәнбер катнашучы белән социаль файдаланудагы наем йортын төзү һәм аннан файдалану максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә төзелмәгән булса.»;



3) түбәндәге эчтәлекле $35^1$ статья өстәргә:

«$35^1$ статья. **Авыл хуҗалыгы оешмаларына һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру өчен даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында яисә гомерлек мирас итеп биләү хокукында бирелгән дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен милеккә алу**

1. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән авыл хуҗалыгы оешмаларына яисә крестьян (фермер) хуҗалыкларына эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру өчен даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында яисә гомерлек мирас итеп биләү хокукында бирелгән җир кишәрлекләре, әгәр мондый кишәрлекләрдә биналар яисә корылмалар булмаса, күрсәтелгән затлар тарафыннан милеккә авыл хуҗалыгының уңдырышлы җирләренең кадастр хакының 10 процентына тигез бәядән алына.

2. Торак пунктлар чикләрендә урнашкан һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен билгеләнгән, авыл хуҗалыгы оешмаларына яисә крестьян (фермер) хуҗалыкларына эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру өчен даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында яисә гомерлек мирас итеп биләү хокукында бирелгән җир кишәрлекләре, әгәр мондый кишәрлекләрдә биналар яисә корылмалар булмаса, күрсәтелгән затлар тарафыннан милеккә аларның кадастр хакының 10 процентына тигез бәядән алына.

3. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән яисә торак пункт җирләреннән бирелгән һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе алып бару өчен билгеләнгән, биналары һәм корылмалары булмаган җир кишәрлеген арендага алучы, шушы арендаторның аренда хокукы мондый җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын яисә гомерлек мирас итеп биләү хокукын аренда хокукына яңадан рәсмиләштерү нәтиҗәсендә барлыкка килгән очракта, мондый җир кишәрлеген кадастр хакының 10 процентына тигез бәядән милеккә алырга хокуклы.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 28 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законындагы 2 статьяны (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 4; 2014, № 5) үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 1 июле
№ 45-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 669. «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш); 2008, № 1, № 12 (VI өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2014, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 26 статьяның 1 пунктына «Татарстан Республикасы Прокуратурасы» сүзләреннән соң «, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» сүзләрен өстәргә;

2) 45 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра.»;



3) 47 статьяның җиденче абзацына «Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы,» сүзләрен өстәргә;

4) VIII бүлек исемендә **«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ,»** сүзләреннән соң **«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘР СОВЕТЫ,»** сүзләрен өстәргә;

5) 55 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«55 статья. **Республика башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы, җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлеге**

1. Республика башкарма хакимият органнары, аларның территориаль органнары үз эшчәнлекләрен районнар, республика әһәмиятендәге шәһәрләр территорияләрендә җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлектә гамәлгә ашыралар, аларның үтенече буенча эшчәнлекләрен гамәлгә ашыруда тиешле ярдәмне күрсәтәләр.

Республика башкарма хакимият органнары, аларның территориаль органнары җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы белән үзара хезмәттәшлек итәләр.

2. Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы, җирле үзидарә органнары теләсә кайсы республика башкарма хакимияте органына һәм аның территориаль органнарына алар карамагындагы мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итәргә хокуклы.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 1 июле
№ 46-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 670. «Татарстан Республикасы дәүләт тормышындагы һәм җирле әһәмияттәге аеруча мөһим мәсьәләләр буенча халык фикер алышуы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт тормышындагы һәм җирле әһәмияттәге аеруча мөһим мәсьәләләр буенча халык фикер алышуы турында» 2003 елның 6 августындагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2005, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә «һәм җирле әһәмияттәге» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 2 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 3 статьяда «һәм җирле әһәмияттәге», «, муниципаль берәмлек уставы, тиешле вәкаләтле җирле үзидарә органнары карарлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 4 статьяның икенче өлешендә «һәм җирле әһәмияттәге» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 5 статьяда «һәм җирле әһәмияттәге», «яисә җирле бюджетлар» сүзләрен төшереп калдырырга;

6) 3 бүлекне үз көчен югалткан дип танырга.



**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 1 июле
№ 47-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 671. «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 1; 2013, № 5, № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемдә «аларны дәвалау,» сүзләреннән соң «хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау,» сүзләрен өстәргә;

2) преамбулада «аларны дәвалау,» сүзләреннән соң «хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау,» сүзләрен өстәргә;

3) 1 статьяның 1 өлешендәге беренче абзацта «аларны дәвалау,» сүзләреннән соң «хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау,» сүзләрен өстәргә;

4) 5 статьяның 2 өлешендә «аларны дәвалау,» сүзләреннән соң «хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау,» сүзләрен өстәргә;

5) кушымтада:

а) «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына кушымта»

сүзләрен

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына кушымта»

сүзләренә алмаштырырга;

б) исемдә «аларны дәвалау,» сүзләреннән соң «хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау,» сүзләрен өстәргә;

в) 2 пунктта «аларны дәвалау,» сүзләреннән соң «хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау,» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 1 июле
№ 48-ТРЗ



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 672. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2015 елның 6 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 3, № 4), түбәндәге эчтәлекле $2^1$ статья өстәп, үзгәреш кертергә:

**«$2^1$ статья**

Татарстан Республикасы территориясендә аз алкогольле тонусны күтәрә торган эчемлекләрне ваклап сату тыела, андый эчемлекләр дигәндә әлеге статья максатлары өчен «Аз алкогольле тонусны күтәрә торган эчемлекләр. Гомуми техник шартлар» ГОСТ Р 52845-2007 Россия Федерациясе милли стандарты нигезендә әзер продукция күләменең 1,2дән 9 процентка кадәрен этил спирты тәшкил иткән, составында кофеин һәм (яисә) башка тонусны күтәрә торган компонентлар була торган алкоголь продукциясе аңлашыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 60 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 1 июле
№ 49-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 673. «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1999 елның 6 декабрендәге 2486 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 2 (2); 2001, № 12; 2004, № 7 (I өлеш); 2005, № 4 (I өлеш); 2008, № 3; 2009, № 9 – 10; 2012, № 1, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 4, № 5, № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 статьяның өченче өлешендә «радиоактив, агулы һәм бүтән төрле куркыныч калдыкларны» сүзләрен «радиоактив калдыкларны, I – V классны хәвефлелектәге калдыкларны» сүзләренә, «агулы һәм бүтән төрле куркыныч калдыклардан» сүзләрен «I – V класслы хәвефлелектәге калдыклардан» сүзләренә алмаштырырга;

2) 14 статьяның икенче өлешендә «кишәрлегендә файдалы казылмаларны» сүзләреннән соң «чит ил инвесторлары контрольлегендәге юридик зат яисә чит ил инвесторы тарафыннан» сүзләрен өстәргә;

3) 16 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү өчен, җир асты суларын чыгару өчен яисә җир асты суларын табу һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү, аларны чыгару өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирү турында.»;



4) 29 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«29 статья. **Җир кишәрлекләре милекчеләренең, җирдән файдаланучы-ларның, җир биләүчеләрнең, җир кишәрлекләрен арендага алучыларның җир кишәрлекләре чикләрендәге гомумтаралган файдалы казылмалардан һәм җир асты суларыннан үз ихтыяҗлары өчен файдалану хокуклары**

Җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир биләүчеләр, җир кишәрлекләрен арендага алучылар үз ихтыяҗлары өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, шартлату эшләрен кулланмыйча, әлеге җир кишәрлекләре чикләрендә табылган һәм дәүләт балансында исәпләнмәгән гомумтаралган файдалы казылмалардан файдаланырга, үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү чыганагы булмаган һәм үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү чыганагы булган җир асты сулыклары өстендә урнашкан җир асты сулыкларыннан тәүлегенә 100 куб метрдан артык булмаган күләмдә җир асты суларыннан файдаланырга, шулай ук биш метр тирәнлеккә кадәр җир асты корылмалары төзергә хокуклы.

Гомумтаралган файдалы казылмалардан һәм җир асты суларыннан үз ихтыяҗлары өчен файдалану дигәндә әлеге статья максатларында җир кишәрлекләре милекчеләренең, җирдән файдаланучыларның, җир биләүчеләрнең, җир кишәрлекләрен арендага алучыларның алардан шәхси, көнкүреш һәм эшкуарлык эшчәнлеген башкаруга бәйле булмаган башка ихтыяҗлар өчен файдалануы аңлашыла.

Җир кишәрлегендә табылган һәм җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир биләүчеләр, җир кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан шәхси, көнкүреш һәм эшкуарлык эшчәнлеген башкаруга бәйле булмаган башка ихтыяҗлар өчен файдаланыла торган гомумтаралган файдалы казылмалар һәм җир асты сулары читләштерелми яисә бер заттан икенчесенә күчә алмый.»;

5) III[1] бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«III[1] бүлек. ҖИРЛЕ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ҖИР АСТЫ БАЙЛЫКЛАРЫ КИШӘРЛЕКЛӘРЕННӘН ФАЙДАЛАНУ ХОКУКЫН БИРҮ**

35[1] статья. **Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын бирү**

Гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен яисә гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукы, әлеге статьяның икенче өлешендәге өченче, дүртенче, алтынчы абзацларында каралган очраклардан тыш, аукцион нәтиҗәләре буенча бирелә.

Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукы аукцион үткәрмичә түбәндәге максатлар өчен бирелә:

файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм региональ әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзү һәм алардан файдалану;

ачык ятмадагы гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару, әлеге ятманың гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында бу җир асты байлыклары кишәрлеген геологик өйрәнү эшләрен үткәргән, әлеге эшләрне дәүләт контракты нигезендә башкарудан тыш, җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан ачылу факты билгеләнгәндә;

файдалану хокукы вакытыннан алда туктатылган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә юридик зат (оператор) тарафыннан эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән кыска сроклы (бер елга кадәр) файдалану;

гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеген геологик өйрәнү;

җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү, җир асты суларын чыгару яисә җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү, аларны чыгару.

Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.



35[2] статья. **Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын аукцион нәтиҗәләре буенча бирү тәртибе**

Әлеге Законның 35[1] статьясындагы беренче өлешендә күрсәтелгән максатларда җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын алу өчен аукционда катнашуга дәгъва кылучы (әлеге статьяда алга таба — мөрәҗәгать итүче) аукционда катнашу өчен җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган рәвештә гариза бирә, шулай ук түбәндәге документларны тапшыра:

мөрәҗәгать итүченең гамәлгә кую документлары күчермәләрен (әгәр мөрәҗәгать итүче юридик зат булса);

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан) өземтәне;

салым түләүченең идентификация номерын күрсәтеп, мөрәҗәгать итүченең салым органында исәпкә куелуы турында таныклыкның күчермәсен;

салымнар һәм җыемнар түләү буенча бурычы булу яисә булмау турында салым органнарыннан белешмәне;

мөрәҗәгать итүченең һәм җәлеп ителәчәк подрядчикларның җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга бәйле эшчәнлек төрләренә лицензияләре (алар булса) күчермәләрен;

соңгы хисап датасына мөрәҗәгать итүченең бухгалтерлык балансы күчермәсен, аңа кабул ителүе хакында салым органы билгесе куелган булырга тиеш;

гариза биргән датага кадәр узган ай дәвамында мөрәҗәгать итүченең счетлары буенча акчалар йөреше турында банк учреждениеләреннән белешмәләрне;

заем яисә кредит шартнамәләренең (алар булса) күчермәләрен;

подряд шартнамәләренең (алар булса) күчермәләрен;

кулланыла торган технологияләр һәм аларның тасвирламалары турында белешмәне һәм мөрәҗәгать итүченең йә җәлеп ителәчәк подрядчикның бораулау, тау эшләрен башкару өчен кирәкле техник чаралары булуын раслый торган исемлеген;

мөрәҗәгать итүченең йә җәлеп ителәчәк подрядчикларның штат расписаниесе күчермәсен;

эшләрне башкарачак квалификацияле белгечләрнең дипломнары күчермәләрен.

Документларның күчермәләре билгеләнгән тәртиптә таныкланырга йә оригиналларын күрсәтеп тапшырылырга тиеш.

Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар үткәрү турында, аукцион комиссиясенең составы һәм эш тәртибе турында карарлар кабул итү һәм җир асты байлыкларының һәр кишәрлегенә яисә җир асты байлыклары кишәрлекләре төркеменә карата мондый аукционнарны үткәрү тәртибен һәм шартларын билгеләү җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

35[3] статья. **Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын аукцион үткәрмичә бирү тәртибе**

Әлеге Законның 35[1] статьясындагы икенче өлешендә күрсәтелгән максатларда җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын алуга дәгъва кылучы (әлеге статьяда алга таба – мөрәҗәгать итүче) әлеге хокукны алу өчен җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган рәвештә гариза бирә.

Мөрәҗәгать итүчегә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турында карар кабул итү өчен әлеге Законның 35[4] – 35[8] статьяларында каралган документлар кирәк. Документларның күчермәләре билгеләнгән тәртиптә таныкланырга йә оригиналларын күрсәтеп тапшырылырга тиеш.

Җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы, гариза һәм кирәкле барлык документлар алынган көннән алып 20 эш көненнән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турында яисә мондый хокукны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә, тиешле карар кабул ителгән вакыттан алып өч эш көне эчендә бу хакта мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә. Бу чакта җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирүдән баш тарту турындагы хәбәрнамә мөрәҗәгать итүчегә, баш тартуның сәбәбләре күрсәтелеп, язма рәвештә җибәрелә (тапшырыла).



35[4] статья. **Файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм региональ әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзү һәм алардан файдалану максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү өчен кирәкле документлар**

Файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм региональ әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзү һәм алардан файдалану максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү өчен әлеге Законның 35[2] статьясындагы беренче өлешендә каралган документлар, шулай ук түбәндәгеләр кирәк:

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия алу өчен дәүләт пошлинасын түләү документы;

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең топографик планы күчермәсе (өч нөсхәдә);

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең гариза бирелгән вакытка торышы яктыртылган һәм эшләр башлауның планлаштырыла торган сроклары һәм җир асты байлыкларын, әйләнә-тирә мохитне саклау буенча тәкъдим ителә торган чаралар турында белешмәләр булган аңлатма;

җир асты корылмасын төзүнең расланган проектыннан төзелеш объектының күләмнәре турында белешмәләр булган өземтә.

Әлеге Законның 35[2] статьясындагы беренче өлешенең икенче, җиденче – унөченче абзацларында, шулай ук әлеге статьяның беренче өлешендәге икенче – бишенче абзацларында каралган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза белән бергә тапшырыла.

Әлеге Законның 35[2] статьясындагы беренче өлешенең өченче – алтынчы абзацларында каралган документлар, әгәр күрсәтелгән документларны мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырмаган булса, җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан мөстәкыйль соратып алына.

35[5] статья. **Ачык ятманың гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында бу җир асты байлыклары кишәрлеген геологик өйрәнү эшләрен үткәргән, эшләрне дәүләт контракты нигезендә башкарудан тыш, җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан ачылу факты билгеләнгәндә, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән ачык ятмадагы гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару максатларында файдалану хокукын бирү өчен кирәкле документлар**

Ачык ятманың гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында бу җир асты байлыклары кишәрлеген геологик өйрәнү эшләрен үткәргән, эшләрне дәүләт контракты нигезендә башкарудан тыш, җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан ачылу факты билгеләнгәндә, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән ачык ятмадагы гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару максатларында файдалану хокукын бирү өчен әлеге Законның 35[2] статьясындагы беренче өлешендә каралган документлар, шулай ук түбәндәгеләр кирәк:

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия алу өчен дәүләт пошлинасын түләү документы;

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең топографик планы күчермәсе (өч нөсхәдә);

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең гариза бирелгән вакытка торышы яктыртылган һәм эшләр башлауның планлаштырыла торган сроклары һәм җир асты байлыкларын, әйләнә-тирә мохитне саклау буенча тәкъдим ителә торган чаралар турында белешмәләр булган аңлатма;

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә гомумтаралган файдалы казылмалар запасларын раслау беркетмәсенең күчермәсе;

мөрәҗәгать итүче гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару өчен файдалана торган эчке елга һәм катнаш («елга-диңгез») йөзү судноларын «ГЛОНАСС» яисә «ГЛОНАСС/GPS» спутник навигациясе аппаратурасы ярдәмендә «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасына тоташтыру өчен җайланма урнаштыру акты күчермәсе (мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән суднолардан файдаланганда);



мөрәҗәгать итүченең файдалануга бирелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләү турында таныклык күчермәсе.

Әлеге Законның 35[2] статьясындагы беренче өлешенең икенче, җиденче —унөченче абзацларында, шулай ук әлеге статьяның беренче өлешендәге икенче —алтынчы абзацларында каралган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза белән бергә тапшырыла.

Әлеге Законның 35[2] статьясындагы беренче өлешенең өченче — алтынчы абзацларында, шулай ук әлеге статьяның беренче өлешендәге җиденче абзацында каралган документлар, әгәр күрсәтелгән документларны мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырмаган булса, җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан мөстәкыйль соратып алына.

35[6] статья. **Файдалану хокукы вакытыннан алда туктатылган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә юридик зат (оператор) тарафыннан эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән кыска сроклы (бер елга кадәр) файдалану максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү өчен кирәкле документлар**

Файдалану хокукы вакытыннан алда туктатылган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә юридик зат (оператор) тарафыннан эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән кыска сроклы (бер елга кадәр) файдалану максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү өчен әлеге Законның 35[2] статьясындагы беренче өлешендә каралган документлар, шулай ук түбәндәгеләр кирәк:

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия алу өчен дәүләт пошлинасын түләү документы;

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең топографик планы күчермәсе (өч нөсхәдә);

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең гариза бирелгән вакытка торышы яктыртылган һәм эшләр башлауның планлаштырыла торган сроклары һәм җир асты байлыкларын, әйләнә-тирә мохитне саклау

буенча тәкъдим ителә торган чаралар турында белешмәләр булган аңлатма;

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә гомумтаралган файдалы казылмаларның расланган запаслары беркетмәсе күчермәсе;

мөрәҗәгать итүче гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару өчен файдалана торган эчке елга һәм катнаш («елга-диңгез») йөзү судноларын «ГЛОНАСС» яисә «ГЛОНАСС/GPS» спутник навигациясе аппаратурасы ярдәмендә «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасына тоташтыру өчен җайланма урнаштыру акты күчермәсе (мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән суднолардан файдаланганда);

Әлеге Законның $35^2$ статьясындагы беренче өлешенең икенче, җиденче –унөченче абзацларында, шулай ук әлеге статьяның беренче өлешендәге икенче –алтынчы абзацларында каралган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза белән бергә тапшырыла.

Әлеге Законның $35^2$ статьясындагы беренче өлешенең өченче – алтынчы абзацларында каралган документлар, әгәр күрсәтелгән документларны мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырмаган булса, җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан мөстәкыйль соратып алына.

$35^7$ статья. **Гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеген геологик өйрәнү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү өчен кирәкле документлар**

Гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеген геологик өйрәнү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү өчен әлеге Законның $35^2$ статьясындагы беренче өлешендә каралган документлар, шулай ук түбәндәгеләр кирәк:

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия алу өчен дәүләт пошлинасын түләү документы;

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең топографик планы күчермәсе (өч нөсхәдә);

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең гариза бирелгән вакытка торышы яктыртылган һәм эшләр башлауның планлаштырыла торган сроклары һәм җир асты байлыкларын, әйләнә-тирә мохитне саклау буенча тәкъдим ителә торган чаралар турында белешмәләр булган аңлатма.



Әлеге Законның $35^2$ статьясындагы беренче өлешенең икенче, җиденче –унөченче абзацларында, шулай ук әлеге статьяның беренче өлешендәге икенче –дүртенче абзацларында каралган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза белән бергә тапшырыла.

Әлеге Законның $35^2$ статьясындагы беренче өлешенең өченче – алтынчы абзацларында каралган документлар, әгәр күрсәтелгән документларны мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырмаган булса, җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан мөстәкыйль соратып алына.

$35^8$ статья. **Җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү өчен, җир асты суларын чыгару өчен яисә җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү, аларны чыгару өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү өчен кирәкле документлар**

Җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү өчен, шулай ук җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү, аларны чыгару өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү өчен әлеге Законның $35^2$ статьясындагы беренче өлешендә каралган документлар, шулай ук түбәндәгеләр кирәк:

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия алу өчен дәүләт пошлинасын түләү документы;

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең топографик планы күчермәсе (өч нөсхәдә);

мөрәҗәгать итүченең файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану шартлары буенча тәкъдимнәре, аларга эшләрнең төрләрен, күләмнәрен, үткәрү вакытын, геологик өйрәнүнең, шул исәптән файдалы казылмалар запасларын арттыру буенча көтелгән нәтиҗәләрен күрсәтеп, файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеген геологик өйрәнү буенча тәкъдимнәр керә;

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеген җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү эшләрен башкаруга дәүләт

контракты күчермәсе (күрсәтелгән эшләр дәүләт контракты нигезендә башкарылган очракта).

Җир асты суларын чыгару өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү өчен әлеге Законның $35^2$ статьясындагы беренче өлешенең икенче — унынчы абзацларында каралган документлар, шулай ук түбәндәгеләр кирәк:

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия алу өчен дәүләт пошлинасын түләү документы;

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең топографик планы күчермәсе (өч нөсхәдә);

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә җир асты сулары запасларын раслау беркетмәсе күчермәсе;

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге турында әлеге статьяның өченче өлешендә күрсәтелгән белешмәләр булган мәгълүмат;

су җыю скважинасы паспорты күчермәсе;

җир асты суларын чыгаруның күрсәтелгән күләмен исәпләү һәм нигезләү;

су объектының санитария кагыйдәләренә һәм су объектыннан халык сәламәтлеге өчен имин файдалану шартларына туры килүе турында санитария-эпидемиологик бәяләмә күчермәсе.

Файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге турында әлеге статьяның икенче өлешендәге бишенче абзацында күрсәтелгән мәгълүматта түбәндәгеләр булырга тиеш:

җир асты байлыклары кишәрлегенең геологик төзелеше турында белешмәләр, шул исәптән файдаланыла торган җир асты сулыгы хакында белешмәләр;

җир асты суларына ихтыяҗны һәм җир асты суларын файдалануның максатчан билгеләнешен дәлилләү;

су әзерләү системасын куллану турында белешмәләр (булган очракта);

җир асты байлыклары кишәрлегендә урнашкан су җыю корылмасы схемасы, скважиналарның географик координаталары;

җир асты байлыклары кишәрлегендә урнашкан скважиналарның конструкцияләре һәм билгеләнеше турында белешмәләр;

су җыю корылмасыннан файдалану режимына характеристика;



чыгарыла торган җир асты суларының күләмен һәм сыйфатын исәпкә алуның һәм тикшерүнең булган чаралары турында белешмәләр;

җир асты байлыклары кишәрлегендә җир асты суларын күрсәтелгән ихтыяҗ күләмендә чыгару мөмкинлеген дәлилләү.

Әлеге Законның $35^2$ статьясындагы беренче өлешенең икенче, җиденче — унынчы абзацларында, әлеге статьяның беренче өлешендәге икенче — дүртенче абзацларында, икенче өлешендәге икенче — җиденче абзацларында каралган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза белән бергә тапшырыла.

Әлеге Законның $35^2$ статьясындагы беренче өлешенең өченче — алтынчы абзацларында, әлеге статьяның беренче өлешендәге бишенче абзацында, икенче өлешендәге сигезенче абзацында каралган документлар, әгәр күрсәтелгән документларны мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырмаган булса, җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органы тарафыннан мөстәкыйль соратып алына.

$35^9$ статья. **Аукционда катнашуга гаризаны йә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын аукцион үткәрмичә алуга гаризаны кабул итүдән баш тарту**

Аукционда катнашуга гаризаны йә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын аукцион үткәрмичә алуга гаризаны кабул итүдән баш тарту түбәндәге очракларда булырга мөмкин:

гариза билгеләнгән таләпләрне бозып бирелгән булса, шул исәптән аның эчтәлеге аукционның игълан ителгән шартларына туры килмәсә;

мөрәҗәгать итүче махсус рәвештә үзе турында дөрес булмаган белешмәләр тапшырган булса;

мөрәҗәгать итүче эшләрне нәтиҗәле һәм имин алып бару өчен үзендә квалификацияле белгечләрнең, кирәкле финанс һәм техник чараларның булуы яисә булачагы турында дәлилләрне тапшырмаган һәм тапшыра алмый торган булса;

әлеге мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирелгән очракта монополиягә каршы законнар таләпләре үтәлми торган булса.»;

6) 73 статьяда:

а) тугызынчы абзацта «радиоактив, зарарлы, агулы матдәләрне һәм җитештерү калдыкларын» сүзләрен «I — V

класслы хәвефлелектәге калдыкларны» сүзләренә алмаштырырга, «(шул исәптән зарарлы һәм агулы матдәләре булганнарын да)» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) уникенче абзацта «яисә сәнәгать сулары белән тәэмин итү максатлары өчен кулланыла торган йә эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү чыганаклары буларак резервлана торган» сүзләрен «(алга таба – эчәр сулар белән тәэмин итү) яисә сәнәгать объектларын йә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларны су белән технологик тәэмин итү яисә эчәр сулар белән тәэмин итү чыганаклары буларак резервлана торган» сүзләренә алмаштырырга;

7) 84 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«84 статья. **Файдалы казылмалар запасларына дәүләт экспертизасы**

Файдалануга бирелә торган җир асты байлыкларыннан рациональ комплекслы файдалану өчен шартлар тудыру, җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүне, җир асты байлыклары кишәрлекләренең чикләрен билгеләү максатларында, разведкаланган ятмаларның файдалы казылмалар запаслары дәүләт экспертизасы узарга тиеш, моңа эчәр сулар белән тәэмин итү яисә сәнәгать объектларын йә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларны су белән технологик тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм аларны чыгару күләме тәүлегенә 100 куб метрдан артмаган җир асты суларын чыгару өчен бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендәге җир асты сулары запаслары керми.

Җир асты байлыкларын файдалы казылмалар чыгару өчен бирү аларның запасларына дәүләт экспертизасы үткәрелгәннән соң гына рөхсәт ителә, моңа эчәр сулар белән тәэмин итү яисә сәнәгать объектларын йә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларны су белән технологик тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм аларны чыгару күләме тәүлегенә 100 куб метрдан артмаган җир асты суларын чыгару өчен бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен бирү керми.

Разведкаланган файдалы казылмалар запасларының сәнәгать әһәмияте турында дәүләт экспертизасы бәяләмәсе аларны дәүләт исәбенә алу өчен нигез булып тора.

Дәүләт экспертизасы ятманы геологик өйрәнүнең теләсә кайсы стадиясендә уздырылырга мөмкин, әмма бу чакта дәүләт экспертизасына тапшырылучы геологик материаллар файдалы казылмалар запасларының күләмен һәм сыйфатын, халык



хуҗалыгындагы әһәмиятен, аларны чыгаруның тауга бәйле техник шартларын, гидрогеологик, экологик һәм башка шартларын объектив бәяләү мөмкинлеген бирергә тиеш.

Файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүгә бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм алардан файдалану өчен яраклы җир асты байлыклары кишәрлекләре турында геологик мәгълүмат та дәүләт экспертизасы узарга тиеш. Җир асты байлыкларының мондый кишәрлекләрен файдалануга бирү геологик мәгълүматка дәүләт экспертизасы үткәрелгәннән соң гына рөхсәт ителә.

Файдалы казылмалар запасларына, файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турында геологик, икътисадый һәм экологик мәгълүматка дәүләт экспертизасы үткәрү федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

8) 86 статьяда:

а) беренче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

б) өченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү (эчәр сулар белән тәэмин итү яисә сәнәгать объектларын йә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларны су белән технологик тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм аларны чыгару күләме тәүлегенә 100 куб метрдан артмаган җир асты суларын чыгарудан тыш) һәм җир асты байлыкларыннан файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда файдалану расланган техник проектлар нигезендә гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, үз көчләренә керүнең әлеге статья белән башка вакытлары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пункты һәм 6 пунктның «а» пунктчасы 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 2 июле
№ 50-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 674. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2012, № 3; 2013, № 1, № 3; 2014, № 1 – 2), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

**«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында**

**Татарстан Республикасы Законы**

1 статья. **Татарстан Республикасында Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

Татарстан Республикасында Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясе Граждан кодексы, Мәдәният турында Россия Федерациясе законнары нигезләре нигезләмәләренә таяна һәм «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон), аның нигезендә кабул ителә торган башка федераль законнар, Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, әлеге Закон, Татарстан Республикасының башка законнары һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары белән гамәлгә ашырыла.



2 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

1. Әлеге Закон Татарстан Республикасында Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) (алга таба – мәдәни мирас объектлары) саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендәге, шул исәптән мәдәни мирас объектларын ачыклау һәм исәпкә алу, мәдәни мирас объектлары сакланышын тәэмин итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне, шулай ук Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә региональ дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруга бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2. Әлеге Законда кулланыла торган терминнар һәм төшенчәләр Федераль законлагы мәгънәләрендә кулланыла.

3 статья. **Мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу;

2) мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендәге Татарстан Республикасы законнары үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

3) законнар нигезендә башка вәкаләтләр.

2. Мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасы вәкаләтләре чикләрендә мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны

популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә дәүләт сәясәтен билгеләү;

2) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына гамәлгә ашыру өчен тапшырылган мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендәге Россия Федерациясе вәкаләтләрен башкару эшчәнлеген Федераль закон нигезендә оештыру;

3) законнар нигезендә башка вәкаләтләр.

3. Мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләү, раслау һәм гамәлгә ашыру;

2) үз вәкаләтләре чикләрендә Татарстан Республикасы милкендәге мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру өлкәсендә дәүләт идарәсен, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын һәм ачыкланган мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавын гамәлгә ашыру;

3) региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының, ачыкланган мәдәни мирас объектларының торышына, аларны тотуга, саклап калуга, алардан файдалануга, аларны популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына региональ дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;

4) Федераль законда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының тарихи-мәдәни әһәмияте категориясен үзгәртү турында карарлар, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының тарихи-мәдәни әһәмияте категориясен үзгәртү хакында карарлар кабул итү;

5) Федераль законның 22 статьясындагы 1 пунктында билгеләнгән очракларда мәдәни мирас объектының тарихи-мәдәни әһәмияте категориясен үзгәртү турында мәдәни мирас объектларын саклауның федераль органы карарларын килештерү;

6) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектын яисә җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертү турында карар кабул итү тәртибен билгеләү;

7) Федераль закон нигезләмәләре нигезендә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау;

8) Татарстан Республикасы территориясендә федераль әһәмияттәге тарихи-мәдәни тыюлык булдыру, аның чикләрен һәм аны тоту режимын раслау турындагы карарны килештерү;

9) региональ әһәмияттәге тарихи-мәдәни тыюлык булдыру турында карар кабул итү, аны тоту режимын раслау;

10) Татарстан Республикасы милкенә яисә муниципаль милеккә карый торган, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән, торышы канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектлары (алга таба — торышы канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектлары) өчен ташламалы аренда түләвен билгеләү тәртибен урнаштыру;

11) законнар нигезендә башка вәкаләтләр.

4 статья. **Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы**

1. Татарстан Республикасы вәкаләтләре чикләрендә мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы чараларын Федераль законда каралмаган функцияләр бирелмәгән, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендәге вәкаләтле органы (алга таба — Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы) гамәлгә ашыра.

2. Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын, ачыкланган мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавы;

2) мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә региональ дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру;

3) Татарстан Республикасы милкендәге мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру;

4) Татарстан Республикасы тарихы һәм мәдәнияте өчен аерым әһәмияткә ия тарихи җирлекләрнең (алга таба — региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр) исемлеген, региональ әһәмияттәге тарихи җирлекнең саклау предметын, региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрен раслау;

5) мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты яисә җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты буларак кертү яисә объектны күрсәтелгән реестрга кертүне кире кагу турында карар кабул итү;

6) региональ әһәмияттәге тарихи-мәдәни тыюлык чикләрен билгеләү;

7) региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата әзерләнгән генераль планнар проектларын, җирләрдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектларын килештерү;

8) Федераль законның $47^3$ статьясындагы 4 пунктында каралган очракта федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын тоту һәм алардан файдалану таләпләрен, Федераль законның $47^3$ статьясындагы 4 пунктында каралган очракта федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларыннан (исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектларыннан тыш) файдалана алуны тәэмин итү таләпләрен, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын саклап калу таләпләрен, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын тоту һәм алардан файдалану таләпләрен, Федераль законның $47^3$ статьясындагы 4 пунктында каралган очракта региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларыннан файдалана алуны тәэмин итү таләпләрен, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын саклап калу таләпләрен, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын тоту һәм алардан файдалану таләпләрен, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларыннан файдалана алуны тәэмин итү таләпләрен билгеләү, Федераль законның $47^6$ статьясындагы 7 пункты нигезендә мәдәни мирас объектлары милекчеләренең яисә башка законлы хуҗаларының саклау йөкләмәләрен әзерләү һәм раслау;

9) истәлекле урын территориясе чикләрендәге һәм Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларында тышкы реклама таратуны тыюны яисә чикләүне, шулай ук Федераль законның $47^6$ статьясындагы 7 пунктында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә аны тарату таләпләрен билгеләү;

10) законнар нигезендә башка вәкаләтләр.



5 статья. **Җирлекләрнең һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

1. Мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә җирлекләрнең һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) җирлекләр һәм шәһәр округлары милкендәге мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру;

2) җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавы;

3) җирле (муниципаль) әһәмияттәге тарихи-мәдәни тыюлыкны оештыру тәртибен билгеләү;

4) ачыкланган мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты буларак кертү турындагы карарны килештерү, шулай ук җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен һәм аннан файдалану режимын килештерү;

5) Федераль законның 22 статьясында билгеләнгән очракларда мәдәни мирас объектының тарихи-мәдәни әһәмияте категориясен үзгәртү турында мәдәни мирас объектларын саклауның федераль органы, Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы карарларын килештерү;

6) җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклау зоналары чикләрен, әлеге зоналар чикләрендә билгеләнә торган җирләрдән файдалану режимын һәм шәһәр төзелеше регламентларын килештерү;

7) әлеге Законда билгеләнгән очракларда муниципаль милектәге мәдәни мирас объектларына карата ташламалы аренда түләвен һәм аның күләмнәрен билгеләү;

8) җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен уздыруга йөкләмә һәм рөхсәт бирү;

9) законнарда каралган башка вәкаләтләр.

2. Җирле үзидарә органнары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы белән тиешле муниципаль берәмлекләр территориясендә урнашкан мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә хезмәттәшлек итү турында килешүләр төзергә хокуклы.

### 6 статья. Мәдәни мирас объектларын саклап калуда, алардан файдалануда, аларны популярлаштыруда һәм дәүләт саклавында иҗтимагый һәм дини берләшмәләрнең ярдәм күрсәтүе

Иҗтимагый һәм дини берләшмәләр дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына мәдәни мирас объектларын саклап калуда, алардан файдалануда, аларны популярлаштыруда һәм дәүләт саклавында Россия Федерациясе законнары нигезендә ярдәм күрсәтергә хокуклы.

### 7 статья. Мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы гамәлләрен финанслау чыганаклары

1. Мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы гамәлләрен финанслау чыганаклары түбәндәгеләр була:

1) федераль бюджет;

2) Татарстан Республикасы бюджеты;

3) бюджеттан тыш акчалар;

4) җирле бюджетлар.

2. Мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы гамәлләрен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре чикләрендә финанслау, Россия Федерациясе тарафыннан тапшырылган вәкаләтләр кысаларында башкарыла торган гамәлләрдән тыш, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына Россия Федерациясе тарафыннан мәдәни мирас объектларына карата тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга акчалар Татарстан Республикасына федераль бюджеттан федераль законнарда каралган күләмдәге субвенцияләр рәвешендә бирелә.

3. Мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы гамәлләрен финанслауга бюджеттан тыш акчалар җәлеп итү һәм аларны тоту федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы үз бюджет акчалары исәбеннән федераль милектәге мәдәни мирас объектларын саклап калу һәм популярлаштыру гамәлләрен финанслауда һәм федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавында катнашырга хокуклы.

5. Татарстан Республикасы һәм Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр үзләренең бюджет акчалары исәбеннән дини оешмалар милкендәге Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларын һәм дини билгеләнештәге ачыкланган мәдәни мирас объектларын саклап калу гамәлләренә финанс ярдәме күрсәтергә хокуклы.

### 8 статья. Мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программалары

1. Мәдәни мирас объектларын саклап калуны, алардан файдалануны, аларны популярлаштыруны һәм дәүләт саклавын тәэмин итү максатларында мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә федераль программалар һәм мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программалары гамәлгә ашырыла.

2. Мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программалары федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә эшләнә, раслана һәм гамәлгә ашырыла.

3. Мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларының заказчысы Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы була.

### 9 статья. Мәдәни мирас объектларын саклап калу эшләренә үз акчаларын керткән физик һәм юридик затларга бирелә торган ташламалар һәм компенсацияләр

1. Татарстан Республикасы милкендәге яисә муниципаль милектәге мәдәни мирас объектына аренда хокукында ия булучы, шушы объектны саклап калуның Федераль законның 40 — 45 статьяларында каралган эшләренә үз акчаларын керткән һәм

Федераль закон, әлеге Закон нигезендә әлеге эшләрнең үтәлешен тәэмин иткән физик яисә юридик зат ташламалы аренда түләвенә хокуклы.

Татарстан Республикасы милкендәге яисә муниципаль милектәге мәдәни мирас объектларына карата ташламалы аренда түләвен һәм аның күләмнәрен билгеләү тиешенчә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә җирле үзидарә органнары тарафыннан үз компетенцияләре чикләрендә башкарыла.

2. Татарстан Республикасы милкендәге яисә муниципаль милектәге мәдәни мирас объектына аренда хокукында ия булучы һәм Федераль закон, әлеге Закон нигезендә шушы объектны саклап калу эшләрен башкаруны тәэмин иткән физик яисә юридик зат тоткан чыгымнар яисә чыгымнарның өлеше суммасына билгеләнгән аренда түләвен киметергә хокуклы.

Күрсәтелгән компенсацияне бирү тәртибе һәм аның күләме аренда шартнамәсе белән билгеләнә.

3. Физик яисә юридик затка ташламалы аренда түләвен бирү йә билгеләнгән аренда түләвен киметү мөмкинлеге турындагы бәяләмә, әлеге затның фикерен исәпкә алып, Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы тарафыннан бирелә.

4. Региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты милекчесе булган йә мәдәни мирас объектыннан түләүсез файдалану шартнамәсе нигезендә файдаланучы һәм үз акчалары исәбеннән аны саклап калу эшләрен башкаручы физик яисә юридик зат мондый эшләрне Федераль закон нигезендә үтәгәндә үзе тоткан чыгымнар өчен компенсация алырга хокуклы.

Компенсация түләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

### 10 статья. **Торышы канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектларын арендага тапшырганда физик һәм юридик затларга бирелә торган ташламалар**

1. Файдаланылмый торган, торышы канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектлары әлеге статьяда билгеләнгән таләпләрне үтәгәндә физик яисә юридик затларга 49 елга кадәр вакытка, ташламалы аренда түләвен билгеләп, түбәндәгечә арендага бирелергә мөмкин:

Татарстан Республикасы милкендәге — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән башкарма хакимият органы карары белән;



муниципаль милектәге — мәдәни мирас объекты урнаша торган территориядәге җирле үзидарә органы карары белән ул үзе билгеләгән тәртиптә.

2. Ташламалы аренда түләве Татарстан Республикасы милкенә яисә муниципаль милеккә караган, торышы канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектын арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион уздыру нәтиҗәләре буенча мондый шартнамә төзелгән көннән билгеләнә.

3. Татарстан Республикасы милкенә яисә муниципаль милеккә караган, торышы канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектларын арендага бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

4. Татарстан Республикасы милкенә яисә муниципаль милеккә караган, торышы канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектын арендалау шартнамәсенең мөһим шарты булып Федераль законның $47^6$ статьясында каралган саклау йөкләмәсе нигезендә арендачының мондый мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен башкару бурычы тора, аларны үтәү вакыты күрсәтелгән мәдәни мирас объектын арендага тапшырган көннән алып җиде елдан артмаска тиеш, моңа мәдәни мирас объектын саклап калуның проект документациясен әзерләү һәм килештерү вакыты да керә, ул шушы объектны арендага тапшырган көннән алып ике елдан артмаска тиеш.

5. Күрсәтелгән шартны арендачы үтәмәгән очракта, шартнамә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә өзелергә тиеш.

6. Татарстан Республикасы милкенә яисә муниципаль милеккә караган, торышы канәгатьләнерлек булмаган, әлеге статьяда каралган аренда шартнамәсе буенча арендачыга бирелгән мәдәни мирас объектын субарендага бирү, аренда шартнамәсе буенча үз хокукларын һәм бурычларын башка затка тапшыру, күрсәтелгән мәдәни мирас объектын түләүсез файдалануга бирү, аренда хокукларының залогы һәм аларны мөлкәт кертеме буларак коммерциячел булмаган оешмаларга яисә пай кертеме буларак җитештерү кооперативларына кертү рөхсәт ителми.

### 11 статья. **Мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектның тарихи-мәдәни кыйммәтен билгеләү эшен оештыру тәртибе**

1. Мәдәни мирас объектларын саклауның федераль органы, мәдәни мирас объектларын саклауның муниципаль органы, физик яисә юридик зат Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органына мәдәни мирас объекты билгеләренә

ия булган объектны Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертү турында гариза (алга таба – гариза) җибәрергә хокуклы.

2. Гариза, объектның урнашкан урыны (объектның адресы яисә ул булмаганда объект урнашкан урынның тасвирламасы) һәм аның тарихи-мәдәни кыйммәте турында белешмәләр күрсәтелеп, язма рәвештә җибәрелә.

3. Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы гаризаны теркәгән көннән алып утыз календарь көн дәвамында мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектны карауны башкаручы затларны күрсәтеп, шушы объектны карауны уздыру, шулай ук мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендәге белгечләрне җәлеп итү турында боерык чыгара.

4. Мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектны карау йомгаклары буенча карау акты төзелә, ул Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органының вазыйфаи затлары, карауны уздырган мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендәге җәлеп ителгән белгечләр тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы җитәкчесе тарафыннан раслана.

5. Карау актында мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектның тарихи-мәдәни кыйммәтен ачыклау йә аның булмавы факты чагылдырыла һәм әлеге объектны ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертү кирәклеге йә кирәк булмавы күрсәтелә.

6. Мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектның тарихи-мәдәни кыйммәтен билгеләү эшләре гаризаны теркәгән көннән алып туксан эш көненнән артмаган вакытта тәмамлана.

7. Мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектны ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертү турындагы карар әлеге статьяның 4 өлешендә күрсәтелгән карау акты нигезендә акт расланган вакыттан алып биш көн дәвамында Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы җитәкчесе тарафыннан кабул ителә.

12 статья. **Региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларында һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларында мәгълүмати язмалар һәм билгеләр урнаштыру тәртибе**

1. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән региональ әһәмияттәге мәдәни мирас



объектларында һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларында мәдәни мирас объекты турында мәгълүмат булган язмалар һәм билгеләр (алга таба – мәгълүмати язмалар һәм билгеләр) урнаштырыла.

Мәгълүмати язмалар һәм билгеләр Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә эшләнгән булырга һәм нык, чыдам материалдан ясалган чыганакта урнаштырылырга тиеш.

2. Региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларында урнаштыру өчен билгеләнгән мәгълүмати язмалар һәм билгеләр Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы белән килештерелгән эскиз проекты нигезендә эшләнә.

Региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектында, кагыйдә буларак, бер мәгълүмати язма һәм бер билге урнаштырыла.

3. Региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларында мәгълүмати язмалар һәм билгеләр шушы объектлар Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән көннән алып бер ел дәвамында урнаштырыла.

Мәдәни мирас объектларында мәгълүмати язмалар һәм билгеләр урнаштыру бурычы объектлар милекчеләренә йөкләнә.

4. Татарстан Республикасы милкендәге яисә муниципаль милектәге региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына карата мәгълүмати язмалар һәм билгеләр әзерләү һәм урнаштыру эшләре мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт программалары һәм муниципаль программалар нигезендә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

5. Мәгълүмати язмалар һәм билгеләр, Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы белән килештереп, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларыннан түбәндәге очракларда сүтеп алынырга мөмкин:

1) мәдәни мирас объектын саклау эшләре (ремонтлау-реставрацияләү эшләре) үткәрелгәндә;

2) мәдәни мирас объектының тарихи-мәдәни әһәмияте категориясе үзгәргәндә йә мәдәни мирас объекты төренә, аның исеменә кагылышлы башка җитди үзгәрешләр булганда мәгълүмати язманы һәм билгене алмаштыру кирәк булганда;

3) мәгълүмати язманың һәм билгенең матди чыганагы физик яктан тузганда;

4) мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдырганда;

5) законнарда каралган башка очракларда.

6. Региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларында мәгълүмати язмалар һәм билгеләр эчтәлегенә, аларны урнаштыру тәртибенә һәм урыннарына карата таләпләр, шулай ук мәгълүмати язмаларны һәм билгеләрне исәпкә алу һәм аларның торышын тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

7. Җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларында мәгълүмати язмалар һәм билгеләр урнаштыру тәртибе муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.

13 статья. **Мәдәни мирас объекты территориясендә һәм мәдәни мирас объектын саклау зоналарында транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү**

1. Мәдәни мирас объектының бөтенлегенә һәм саклануына куркыныч булганда, мәдәни мирас объекты территориясендә һәм мәдәни мирас объектын саклау зоналарында транспорт чаралары хәрәкәте чикләнә яисә тыела.

2. Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектының, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектының бөтенлеген һәм сакланышын бозу куркынычы барлыкка килгәндә, федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясендә һәм күрсәтелгән объектларны саклау зоналарында транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү яисә тыю турындагы тәкъдимнәр физик һәм юридик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органына җибәрелә.

3. Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясендә һәм күрсәтелгән объектларны саклау зоналарында транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү яисә тыю турындагы карар Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы тәкъдиме буенча әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән тәкъдимнәрне алган көннән утыз календарь көн дәвамында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителә.

4. Җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясендә һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклау зоналарында транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү яисә тыю турындагы карар мәдәни мирас объекты урнаша торган территориядәге җирле үзидарә органы тарафыннан ул үзе билгеләгән тәртиптә кабул ителә.

5. Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясендә һәм



күрсәтелгән объектларны саклау зоналарында транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү турындагы карар федераль башкарма хакимиятнең юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге органының территориаль органы белән килештереп кабул ителә.

6. Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясендә һәм күрсәтелгән объектларны саклау зоналарында транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү яисә тыю турындагы карарда транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү яисә тыю сроклары һәм шартлары каралырга тиеш.

14 статья. **Мәдәни мирас объектларын саклау зоналары чикләрен, мәдәни мирас объектларын саклауның берләштерелгән зонасы чикләрен раслау**

1. Мәдәни мирас объектларын саклау зоналары чикләре, шул исәптән мәдәни мирас объектларын саклауның берләштерелгән зонасы чикләре (Россия Федерациясе халыкларының аеруча кыйммәтле мәдәни мирас объектларын һәм Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгән мәдәни мирас объектларын саклау зоналары чикләреннән тыш), әлеге зоналар территорияләре чикләрендәге җирләрдән файдалануның махсус режимнары һәм әлеге зоналар территорияләре чикләрендәге шәһәр төзелеше регламентларына таләпләр дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай бәяләмәсен алган мәдәни мирас объектларын саклау зоналары проектлары йә мәдәни мирас объектларын саклауның берләштерелгән зонасы проекты нигезендә, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендәге вәкаләтле органы, мәдәни мирас объекты урнаша торган территориядәге муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы белән килештереп, Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

2. Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына карата мәдәни мирас объектларын саклау зоналары чикләрен, шул исәптән мәдәни мирас объектларын саклауның берләштерелгән зонасы чикләрен (Россия Федерациясе халыкларының аеруча кыйммәтле мәдәни мирас объектларын һәм Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгән мәдәни мирас объектларын саклау зоналары чикләреннән тыш), әлеге зоналар территорияләре чикләрендәге җирләрдән файдалануның махсус режимнарын һәм әлеге зоналар территорияләре чикләрендәге шәһәр төзелеше регламентла-

рына таләпләрне раслау, мәдәни мирас объектларын саклауның федераль органы белән килештереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

### 15 статья. **Региональ әһәмияттәге тарихи-мәдәни тыюлык оештыру тәртибе, аның чикләрен һәм аны тоту режимын билгеләү**

1. Региональ әһәмияттәге тарихи-мәдәни тыюлык төзү, аны тоту режимын раслау турындагы карар дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы бәяләмәсе нигезендә әлеге тыюлык урнаша торган территориядәге муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы белән килештерелгән Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителә.

2. Региональ әһәмияттәге тарихи-мәдәни тыюлыклар чикләре тарихи-мәдәни терәк планы һәм (яисә) тәкъдим ителә торган чикләрне нигезли торган башка документлар һәм материаллар нигезендә Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы тарафыннан билгеләнә.

### 16 статья. **Региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр исемлеген, региональ әһәмияттәге тарихи җирлекнең саклау предметын һәм региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чиген раслау тәртибе**

1. Региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр исемлеге Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы тарафыннан раслана.

2. Региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр исемлегенә чикләрендә Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары һәм тарихи җирлекнең саклау предметын тәшкил итә торган объектлар урнашкан һәм Татарстан Республикасы тарихы һәм мәдәнияте өчен аерым әһәмияткә ия булган торак пункт яисә аның өлеше (алга таба – торак пункт яисә аның өлеше) керә.

3. Торак пунктны яисә аның өлешен региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр исемлегенә кертү инициативасы белән Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органына дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик һәм физик затлар мөрәҗәгать итә ала.



4. Торак пунктны яисә аның өлешен региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр исемлегенә кертү турында карар кабул итү өчен түбәндәгеләр тапшырылырга тиеш:

1) торак пункт яисә аның өлеше турында кыскача тарихи белешмә;

2) торак пунктның яисә аның өлешенең тарихи-мәдәни терәк планы;

3) торак пункт яисә аның өлеше территориясендә урнашкан Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектлары һәм ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлеге;

4) Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларының һәм ачыкланган мәдәни мирас объектларының, торак пункт яисә аның өлеше панорамаларының, торак пунктның яисә аның өлешенең әйләнә-тирә ландшафтының тарихи һәм хәзерге фотофиксация материаллары;

5) тарихи кыйммәткә ия шәһәр барлыкка китерә торган объектларның – тарихи корылышны барлыкка китерә торган һәм шул исәптән масштаб, күләм, структура, стиль, конструктив материаллар, төсле бизәлеш һәм декоратив элементлар нигезендә берләштерелгән биналарның һәм корылмаларның тасвирламасы һәм тарихи һәм хәзерге фотофиксация материаллары;

6) торак пунктның яисә аның өлешенең планировка структурасы, аның элементларын да кертеп, тасвирламасы;

7) торак пунктның яисә аның өлешенең күләм-пространство структурасы тасвирламасы;

8) торак пунктны яисә аның өлешен төзү композициясе һәм силуэты – вертикаль һәм горизонталь доминанталарның һәм акцентларның нисбәте тасвирламасы;

9) торак пунктның яисә аның өлешенең төрле шәһәр киңлекләре (буш, төзелеп беткән, яшелләндерелгән) арасындагы нисбәте тасвирламасы;

10) торак пунктның яисә аның өлешенең композиция-күренеш бәйләнешләре (панорамалары), табигый һәм кеше барлыкка китергән әйләнә-тирәнең нисбәте тасвирламасы;

11) региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясенең күздә тотыла торган чикләре тасвирламасы һәм аларның кимендә 1:10000 масштабтагы картографик сурәте.

5. Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы әлеге статьяның 4 өлешендә күрсәтелгән материалларны һәм документларны аларны тапшырган көннән алып дүрт

ай дәвамында карый һәм торак пунктны яисә аның өлешен региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр исемлегенә кертү турында йә кертүне кире кагу хакында карар кабул итә. Торак пунктны яисә аның өлешен региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр исемлегенә кертү кире кагылган очракта, карарда кире кагу сәбәпләре нигезләп күрсәтелә.

6. Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы үзе торак пунктны яисә аның өлешен региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр исемлегенә кертү инициативасы белән чыгарга хокуклы. Бу очракта әлеге статьяның 4 өлешендә күрсәтелгән материаллар һәм документлар Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы тарафыннан әзерләнә.

7. Торак пунктны яисә аның өлешен региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр исемлегенә кертүне кире кагу өчен түбәндәгеләр нигез була:

1) торак пунктның яисә аның өлешенең әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән критерийларга туры килмәве;

2) әлеге статьяның 4 өлешендә күрсәтелгән материалларны һәм документларны тапшырмау яисә тулы күләмдә тапшырмау;

3) региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләре проектының тарихи җирлек территориясе чикләрен билгеләүгә карата Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган таләпләргә туры килмәве.

8. Торак пунктны яисә аның өлешен региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр исемлегенә кертүне кире кагу турындагы карар, кире кагу сәбәпләрен нигезләп, язма бәяләмә рәвешендә рәсмиләштерелә һәм мондый карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне дәвамында мөрәҗәгать инициаторына җибәрелә.

9. Торак пунктны яисә аның өлешен региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр исемлегенә кертүне кире кагуга китергән сәбәпләр бетерелгәннән соң, мөрәҗәгать инициаторы документларны һәм материалларны әлеге статьяда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органына яңадан җибәрергә хокуклы.

10. Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы актының күчермәсе торак пунктны яисә аның өлешен региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр исемлегенә кертү турындагы карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне дәвамында мөрәҗәгать инициаторына җибәрелә.

11. Региональ әһәмияттәге тарихи җирлекнең саклау предметы һәм региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләре әлеге статьяның 3 – 10 өлешләрендә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы тарафыннан раслана.



12. Региональ әһәмияттәге тарихи җирлекнең саклау предметы Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы тарафыннан һәр региональ әһәмияттәге тарихи җирлеккә карата раслана.

13. Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясенең торак пункт чикләре белән туры килми торган чикләрен расларга хокуклы.

17 статья. **Региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясенә карата әзерләнгән җирләрдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләрен килештерү тәртибе**

1. Региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата әзерләнгән генераль планнар проектлары, җирләрдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектлары Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы белән килештерелергә тиеш.

2. Җирле үзидарәнең шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтле органы региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясенә карата әзерләнгән җирләрдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын (алга таба – проект) муниципаль берәмлек башлыгына җибәргәнче, проектны Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органына килештерү өчен җибәрә.

3. Проектның региональ әһәмияттәге тарихи җирлекнең расланган саклау предметына туры килүе проектның килештерү предметы була.

4. Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы әлеге статьяның 2 өлеше нигезендә тапшырылган проектны карау нәтиҗәләре буенча ул кергән көннән алып утыз көн дәвамында проектны килештерә йә аны килештерүдән баш тарта һәм тиешле бәяләмә бирә. Проектны килештерүдән баш тарткан очракта, бәяләмәдә баш тарту сәбәпләре нигезләп күрсәтелә.

5. Тапшырылган проектны килештерүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

1) проектта Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектлары турында, ачыкланган мәдәни мирас объектлары хакында яисә

региональ әһәмияттәге тарихи җирлекнең саклау предметын тәшкил итә торган объектлар турында белешмәләрнең булмавы йә дөрес булмаган яисә төгәл булмаган белешмәләрнең булуы;

2) проектның Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары һәм региональ әһәмияттәге тарихи җирлекнең саклау предметын тәшкил итә торган объектлар сакланышын тәэмин итү максатларына һәм шартларына туры килмәве;

3) проектның региональ әһәмияттәге тарихи җирлекнең расланган саклау предметына туры килмәве.

6. Проектны килештерүдән баш тарту турындагы бәяләмәдә бәян ителгән искәрмәләр бетерелгәннән соң, җирле үзидарәнең шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтле органы проектны Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органына килештерү өчен яңадан тапшырырга хокуклы. Бу очракта проектны килештерү Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы тарафыннан җирле үзидарә органы яңадан мөрәҗәгать иткән көннән алып утыз календарь көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

7. Проектны килештерү аның мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендәге законнар таләпләренә туры килүе турындагы язмача бәяләмә рәвешендә Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы тарафыннан рәсмиләштерелә.

### 18 статья. **Юкка чыккан мәдәни мирас объектын торгызу**

1. Татарстан Республикасында юкка чыккан мәдәни мирас объектын торгызу махсус очракларда күрсәтелгән объектның аерым тарихи, архитектура, фәнни, сәнгать, шәһәр төзелеше, эстетик яисә башка әһәмияте булганда һәм аны торгызу өчен кирәкле фәнни белешмәләр җитәрлек булганда гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасында юкка чыккан мәдәни мирас объектын федераль бюджет акчалары исәбеннән торгызу турындагы карар дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы бәяләмәсенә нигезләнгән һәм Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы белән килештерелгән мәдәни мирас объектларын саклауның федераль органы тәкъдиме буенча, җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алып, ә дини билгеләнештәге ядкарь яисә ансамбль торгызылган очракта, дини оешмалар фикерен исәпкә алып, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан кабул ителә.



3. Татарстан Республикасында юкка чыккан мәдәни мирас объектын Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән, шулай ук бюджеттан тыш акчалар исәбеннән торгызу турындагы карар Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителә. Юкка чыккан мәдәни мирас объектын торгызу турындагы тәкъдим Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы тарафыннан ул үзе билгеләгән тәртиптә әзерләнә.

4. Юкка чыккан мәдәни мирас объектын Татарстан Республикасында муниципаль берәмлек бюджеты акчалары исәбеннән торгызу турындагы карар мондый мәдәни мирас объекты урнашкан территориядәге муниципаль берәмлекнең муниципаль хокукый акты нигезендә кабул ителә.

### 19 статья. **Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектларын популярлаштыру**

1. Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектларын популярлаштыруны оештыру мәдәни мирас объектларын саклауның федераль органы, Россия Федерациясе дәүләт хакимиятенең башка кызыксынучы органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, иҗтимагый оешмалар, җирле үзидарә органнары, шулай ук юридик һәм физик затлар катнашында Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектларын популярлаштыруны мәдәни мирас объектларына физик тәэсир итү юлы белән гамәлгә ашыручы юридик һәм физик затлар, иҗтимагый оешмалар федераль законнарда һәм әлеге Законда билгеләнгән мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавы, аларны саклап калу һәм алардан файдалану таләпләрен үтәргә тиеш.

### 20 статья. **Мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендәге законнарны бозган өчен җаваплылык**

Мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендәге законнарны бозган өчен вазыйфаи, физик һәм юридик затлар

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплы булалар.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә, шулай ук әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган Татарстан Республикасының норматив хокукый актларын әзерләүне һәм кабул итүне тәэмин итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 2 июле
№ 51-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 675. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 24 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 3), аңа түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

«4. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашырганда үзләрендә спорт әзерлеге узучы затларның сәламәтлеген саклау өчен шартлар тудыралар, шулай ук спорт әзерлеге узучы һәм спорт әзерлеген гамәлгә ашырмый торган физкультура-спорт оешмасы белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаучы затлар белән алар спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда спорт әзерлеге узган вакытта, шул исәптән спорт әзерлеге буенча гамәлгә ашырыла торган программаларда каралган спорт ярышларында катнашу вакытында булган бәхетсезлек очракларын тикшерүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәләр. Күрсәтелгән бәхетсезлек очракларын тикшерү һәм исәпкә алу Федераль закон нигезендә башкарыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 2 июле
№ 52-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 676. Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 16 һәм 28 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 16 статьяның 1 өлешендә:
а) 1 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) шәхсән яисә ышанычлы затлар аркылы эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, федераль законнарда башкасы каралмаган булса яисә федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль хокукый актта билгеләнгән тәртиптә аңа хуҗалык итүче субъект белән идарә итүдә катнашу йөкләнмәгән булса, мондый оешма белән идарә итүдә (торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары, күчемсез милек хуҗалары ширкәтләре һәм билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һөнәр берлекләре моңа керми) катнашырга;»;

2) 28 статьяның 10 өлешендәге 1 пунктында «яшәү урының,» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 2 июле
№ 53-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 677. «Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» 2005 елның 7 декабрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясындагы икенче өлешенең беренче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (I өлеш); 2007, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2013, № 7), «күп дигәндә 100 кеше яшәсә» сүзләрен «күп дигәндә 300 кеше яшәсә» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 2 июле
№ 54-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 678. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 10 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1, № 9 (II өлеш); 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяда:

а) 1 өлештә «(башка төр дәүләт хезмәте)» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 5 өлешнең сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте стажын билгеләгәндә шулай ук тиешле вазыйфаи төркемнәрнең федераль дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларында, хәрби вазыйфаларда һәм хокук саклау хезмәте вазыйфаларында, дәүләт вазыйфаларында, муниципаль вазыйфаларда, тиешле вазыйфаи төркемнәрнең муниципаль хезмәт вазыйфаларында, федераль законнар нигезендә башка вазыйфаларда эш стажы исәпкә алына.»;

2) 17 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы, шулай ук үз гаиләсе әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне яллаучы вәкиленә түбәндәгеләр тапшыра:

1) дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче граждан — хезмәткә кергәндә;

2) Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән билгеләнгән исемлеккә кертелгән дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче дәүләт хезмәткәре — ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 2 июле
№ 55-ТРЗ



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 679. «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2014 елның 27 ноябрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 11 (V өлеш), № 11 (VI өлеш); 2015, № 1 — 2) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 1 өлешендә:

а) 1 пунктта «149 313 085,1» саннарын «172 875 344,3» саннарына алмаштырырга;

б) 2 пунктта «154 792 183,6» саннарын «190 541 414,2» саннарына алмаштырырга;

в) 3 пунктта «5 479 098,5» саннарын «17 666 069,9» саннарына алмаштырырга;

2) 2 статьяда:

а) 1 өлештә «89 733 895,7» саннарын «95 416 727,4» саннарына алмаштырырга;

б) 2 өлештә «97 833 895,7» саннарын «103 516 727,4» саннарына алмаштырырга;

в) 3 өлештә «111 633 895,7» саннарын «117 316 727,4» саннарына алмаштырырга;

г) 4 өлештә:

икенче абзацта «122 871 347,7» саннарын «128 731 179,4» саннарына алмаштырырга;

өченче абзацта «110 767 572,7» саннарын «117 530 404,4» саннарына алмаштырырга;

дүртенче абзацта «132 956 164,0» саннарын «133 796 727,4» саннарына алмаштырырга;

3) 8 статьяның 3 өлешендә «18 970 117,6» саннарын «17 495 087,6» саннарына алмаштырырга;

4) түбәндәге эчтәлекле 9[1] статья өстәргә:
« **9[1] статья**

Дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт унитар предприятиеләре булып тормаган юридик затларга 2015 елга Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет инвестицияләрен әлеге Законга 9[1] кушымта нигезендә расларга.»;

5) 13 статьяда:
а) 1 өлештә «33» саннарын «33[1]» саннарына алмаштырырга;
б) 2 өлештә «33» саннарын «33[1]» саннарына алмаштырырга;

6) 14 статьяның 2 өлешендә:
а) беренче абзацта «6 650 740,1» саннарын «6 696 701,2» саннарына алмаштырырга;
б) икенче абзацта «918 085,6» саннарын «853 004,6» саннарына алмаштырырга;

7) 15 статьяда «12 069 539,2» саннарын «12 256 628,2» саннарына алмаштырырга;

8) түбәндәге эчтәлекле 17[1] статья өстәргә:
« **17[1] статья**

1. 2015 елда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетлар кытлыкларын өлешчә каплау өчен бер елга 10 000,0 мең сумга кадәр бюджет кредитлары бирелә дип билгеләргә.
2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән кредитлардан файдаланган өчен бюджет кредитлары бирү турында шартнамәләр төзү көненә Россия Федерациясе Үзәк банкының гамәлдәге рефинанслау ставкасының икедән бере күләмендә түләү билгеләргә.
3. Бюджет кредитлары муниципаль берәмлекләргә бюджет кредитларын кайтару, тиешле шартнамәләрдә каралган процентларны түләү һәм башка түләүләрне башкару буенча алар тарафыннан үз йөкләмәләрен үтәүнең тәэмин ителешеннән башка бирелә.



4. Бюджет кредитлары муниципаль берәмлекләргә әлеге Законда каралган шартларда һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә, Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының башка норматив актлары нигезләмәләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе граждан законнарына таянып төзелгән шартнамәләр нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бирелә.»;

9) 19 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«**19 статья**

Татарстан Республикасы бюджетында түбәндәгеләрдән алына торган бюджетара трансфертларны һәм кире кайтарылмый торган акчаларны әлеге Законга 34 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга:
федераль бюджеттан 2015 елда 24 283 088,4 мең сум, 2016 елда 11 430 456,0 мең сум һәм 2017 елда 13 949 165,3 мең сум күләмендә;
Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминият фонды бюджетыннан 2015 елда 645 379,7 мең сум күләмендә;
Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан 2015 елда 63,2 мең сум күләмендә;
дәүләт корпорациясеннән – Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм фондыннан 2015 елда 1 270 032,2 мең сум, 2016 елда 1 096 232,0 мең сум һәм 2017 елда 350 734,0 мең сум күләмендә.»;

10) 23 статьяга түбәндәге эчтәлекле 2[1] пункт өстәргә:
«2[1]) «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) 23 статьясындагы 12 өлешенең беренче абзацын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш);»;

11) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2015 елга, 2016 һәм
2017 еллар план чорына
Татарстан Республикасы
бюджеты турында» Татарстан
Республикасы Законына
1 нче кушымта

1 нче таблица

## 2015 елга
## Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары

(мең сумнарда)

| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы |
|---|---|---|
| 01 00 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслау чыганаклары | 17 666 069,9 |
| 01 03 00 00 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджет кредитлары | 15 745 100,0 |
| 01 03 01 00 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитлары | 15 745 100,0 |
| 01 03 01 00 00 0000 700 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары алу | 140 954 552,0 |
| 01 03 01 00 02 0000 710 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына кредитлар алу | 140 954 552,0 |
| 01 03 01 00 00 0000 800 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган бюджет кредитларын каплау | -125 209 452,0 |
| 01 03 01 00 02 0000 810 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган кредитларны Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан каплау | -125 209 452,0 |
| 01 05 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар чараларын исәпкә алу счетларында калган чараларны үзгәртү | 1 925 652,3 |
| 01 05 00 00 00 0000 500 | Бюджетларның калган чараларын арттыру | -342 975 933,9 |
| 01 05 02 00 00 0000 500 | Бюджетларның калган башка чараларын арттыру | -342 975 933,9 |
| 01 05 02 01 00 0000 510 | Бюджетларның калган башка акчаларын арттыру | -342 975 933,9 |
| 01 05 02 01 02 0000 510 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының калган башка акчаларын арттыру | -342 975 933,9 |
| 01 05 00 00 00 0000 600 | Бюджетларның калган чараларын киметү | 344 901 586,2 |



| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы |
|---|---|---|
| 01 05 02 00 00 0000 600 | Бюджетларның калган башка чараларын киметү | 344 901 586,2 |
| 01 05 02 01 00 0000 610 | Бюджетларның калган башка акчаларын киметү | 344 901 586,2 |
| 01 05 02 01 02 0000 610 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының калган башка акчаларын киметү | 344 901 586,2 |
| 01 06 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслауның башка чыганаклары | -4 682,4 |
| 01 06 01 00 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль милектәге акцияләр һәм капиталда катнашуның бүтән рәвешләре | 5 000,0 |
| 01 06 01 00 00 0000 630 | Дәүләт һәм муниципаль милектәге акцияләрне һәм капиталда катнашуның бүтән рәвешләрен сатудан акчалар | 5 000,0 |
| 01 06 01 00 02 0000 630 | Россия Федерациясе субъектлары милкендәге акцияләрне һәм капиталда катнашуның бүтән рәвешләрен сатудан акчалар | 5 000,0 |
| 01 06 04 00 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне үтәү | -29 140 720,0 |
| 01 06 04 01 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне Россия Федерациясе валютасында үтәү | -21 875 000,0 |
| 01 06 04 01 00 0000 800 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән йә бенефициарның принципалга карата таләбе хокуклары гарантка биреп торылган очракта, дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне Россия Федерациясе валютасында үтәү | -21 875 000,0 |
| 01 06 04 01 02 0000 810 | Россия Федерациясе субъектлары дәүләт гарантияләрен гарант тарафыннан үтәү гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукын барлыкка китергән йә бенефициарның принципалга карата таләбе хокуклары гарантка биреп торылган очракта, Россия Федерациясе субъекты дәүләт гарантияләрен Россия Федерациясе валютасында үтәү | -21 875 000,0 |
| 01 06 04 02 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне чит ил валютасында үтәү | -7 265 720,0 |
| 01 06 04 02 00 0000 800 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән очракта, максатчан чит ил кредитларыннан (хисаплашулардан) файдалану кысаларында Россия Федерациясенә бирелгән дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне чит ил валютасында үтәү | -7 265 720,0 |

| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы |
|---|---|---|
| 01 06 04 02 02 0000 820 | Россия Федерациясе субъекты дәүләт гарантияләрен гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән очракта, максатчан чит ил кредитларыннан (хисаплашулардан) файдалану кысаларында Россия Федерациясенә бирелгән Россия Федерациясе субъекты дәүләт гарантияләрен чит ил валютасында үтәү | -7 265 720,0 |
| 01 06 05 00 00 0000 000 | Ил эчендә Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитлары | -9 682,4 |
| 01 06 05 00 00 0000 600 | Ил эчендә Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 317,6 |
| 01 06 05 01 00 0000 600 | Юридик затларга Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 317,6 |
| 01 06 05 01 02 0000 640 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетыннан юридик затларга Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 317,6 |
| 01 06 05 00 00 0000 500 | Ил эчендә Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары бирү | -10 000,0 |
| 01 06 05 02 00 0000 500 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары бирү | -10 000,0 |
| 01 06 05 02 02 0000 540 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Россия Федерациясе субъектлары бюджетыннан Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары бирү | -10 000,0 |
| 01 06 08 00 00 0000 000 | Ил эчендә бирелгән башка бюджет кредитлары (ссудалары) | 29 140 720,0 |
| 01 06 08 00 00 0000 600 | Ил эчендә бирелгән башка бюджет кредитларын (ссудаларын) кире кайтару | 29 140 720,0 |
| 01 06 08 00 02 0000 640 | Ил эчендә Россия Федерациясе субъектлары бюджетыннан бирелгән башка бюджет кредитларын (ссудаларын) кире кайтару | 29 140 720,0 |
| Барлык чыганаклар | | 17 666 069,9 |



2 нче таблица

## 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары

(мең сумнарда)

| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы | |
|---|---|---|---|
| | | 2016 ел | 2017 ел |
| 01 00 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслау чыганаклары | 8 609 671,7 | 14 338 946,4 |
| 01 03 00 00 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджет кредитлары | 8 100 000,0 | 13 800 000,0 |
| 01 03 01 00 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитлары | 8 100 000,0 | 13 800 000,0 |
| 01 03 01 00 00 0000 700 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары алу | 140 113 677,0 | 151 280 000,0 |
| 01 03 01 00 02 0000 710 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына кредитлар алу | 140 113 677,0 | 151 280 000,0 |
| 01 03 01 00 00 0000 800 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган бюджет кредитларын каплау | -132 013 677,0 | -137 480 000,0 |
| 01 03 01 00 02 0000 810 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган кредитларны Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан каплау | -132 013 677,0 | -137 480 000,0 |
| 01 05 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар чараларын исәпкә алу счетларында калган чараларны үзгәртү | 504 671,7 | 533 946,4 |
| 01 05 00 00 00 0000 500 | Бюджетларның калган чараларын арттыру | -301 535 664,5 | -318 944 246,3 |

| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы | |
|---|---|---|---|
| | | 2016 ел | 2017 ел |
| 01 05 02 00 00 0000 500 | Бюджетларның калган башка чараларын арттыру | -301 535 664,5 | -318 944 246,3 |
| 01 05 02 01 00 0000 510 | Бюджетларның калган башка акчаларын арттыру | -301 535 664,5 | -318 944 246,3 |
| 01 05 02 01 02 0000 510 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының калган башка акчаларын арттыру | -301 535 664,5 | -318 944 246,3 |
| 01 05 00 00 00 0000 600 | Бюджетларның калган чараларын киметү | 302 040 336,2 | 319 478 192,7 |
| 01 05 02 00 00 0000 600 | Бюджетларның калган башка чараларын киметү | 302 040 336,2 | 319 478 192,7 |
| 01 05 02 01 00 0000 610 | Бюджетларның калган башка акчаларын киметү | 302 040 336,2 | 319 478 192,7 |
| 01 05 02 01 02 0000 610 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының калган башка акчаларын киметү | 302 040 336,2 | 319 478 192,7 |
| 01 06 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслауның башка чыганаклары | 5 000,0 | 5 000,0 |
| 01 06 01 00 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль милектәге акцияләр һәм капиталда катнашуның бүтән рәвешләре | 5 000,0 | 5 000,0 |
| 01 06 01 00 00 0000 630 | Дәүләт һәм муниципаль милектәге акцияләрне һәм капиталда катнашуның бүтән рәвешләрен сатудан акчалар | 5 000,0 | 5 000,0 |
| 01 06 01 00 02 0000 630 | Россия Федерациясе субъектлары милкендәге акцияләрне һәм капиталда катнашуның бүтән рәвешләрен сатудан акчалар | 5 000,0 | 5 000,0 |
| 01 06 04 00 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне үтәү | -7 265 720,0 | -7 265 720,0 |
| 01 06 04 02 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне чит ил валютасында үтәү | -7 265 720,0 | -7 265 720,0 |



| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы | |
|---|---|---|---|
| | | 2016 ел | 2017 ел |
| 01 06 04 02 00 0000 800 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән очракта, максатчан чит ил кредитларыннан (хисаплашулардан) файдалану кысаларында Россия Федерациясенә бирелгән дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне чит ил валютасында үтәү | -7 265 720,0 | -7 265 720,0 |
| 01 06 04 02 02 0000 820 | Россия Федерациясе субъекты дәүләт гарантияләрен гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән очракта, максатчан чит ил кредитларыннан (хисаплашулардан) файдалану кысаларында Россия Федерациясенә бирелгән Россия Федерациясе субъекты дәүләт гарантияләрен чит ил валютасында үтәү | -7 265 720,0 | -7 265 720,0 |
| 01 06 08 00 00 0000 000 | Ил эчендә бирелгән башка бюджет кредитлары (ссудалары) | 7 265 720,0 | 7 265 720,0 |
| 01 06 08 00 00 0000 600 | Ил эчендә бирелгән башка бюджет кредитларын (ссудаларын) кире кайтару | 7 265 720,0 | 7 265 720,0 |
| 01 06 08 00 02 0000 640 | Ил эчендә Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары тарафыннан бирелгән башка бюджет кредитларын (ссудаларын) кире кайтару | 7 265 720,0 | 7 265 720,0 |
| Барлык чыганаклар | | 8 609 671,7 | 14 338 946,4»; |

12) 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2015 елга, 2016 һәм
2017 еллар план чорына
Татарстан Республикасы
бюджеты турында» Татарстан
Республикасы Законына
2 нче кушымта

1 нче таблица

## 2015 елга Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашулары программасы

(мең сумнарда)

| | Суммасы |
|---|---|
| Эчке дәүләт хисаплашулары | |
| җәлеп итү | 140 954 552,0 |
| бурычның төп суммасын каплауга җибәрелә торган акчалар күләме | 125 209 452,0 |
| шул исәптән: | |
| бюджет кредитлары | |
| җәлеп итү | 140 954 552,0 |
| бурычның төп суммасын каплауга җибәрелә торган акчалар күләме, | 125 209 452,0 |
| шул исәптән: | |
| Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында калган акчаларга өстәү өчен федераль бюджеттан бюджет кредитлары | |
| җәлеп итү | 125 147 000,0 |
| бурычның төп суммасын каплауга җибәрелә торган акчалар күләме | 125 147 000,0 |

2 нче таблица

## 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашулары программасы

(мең сумнарда)

| | Суммасы | |
|---|---|---|
| | 2016 ел | 2017 ел |
| Эчке дәүләт хисаплашулары | | |
| җәлеп итү | 140 113 677,0 | 151 280 000,0 |
| бурычның төп суммасын каплауга җибәрелә торган акчалар күләме | 132 013 677,0 | 137 480 000,0 |



| | | |
|---|---|---|
| шул исәптән: | | |
| бюджет кредитлары | | |
| җәлеп итү | 140 113 677,0 | 151 280 000,0 |
| бурычның төп суммасын каплауга җибәрелә торган акчалар күләме, | 132 013 677,0 | 137 480 000,0 |
| шул исәптән: | | |
| Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында калган акчаларга өстәү өчен федераль бюджеттан бюджет кредитлары | | |
| җәлеп итү | 129 800 000,0 | 133 100 000,0 |
| бурычның төп суммасын каплауга җибәрелә торган акчалар күләме | 129 800 000,0 | 133 100 000,0»; |

13) 3 нче кушымтаның 1 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 нче таблица

## 2015 елга Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәре

(мең сумнарда)

| Исеме | Керем коды | Суммасы |
|---|---|---|
| Салым керемнәре һәм салым булмаган керемнәр | 1 00 00000 00 0000 000 | 146 571 819,9 |
| Табышка, керемнәргә салымнар | 1 01 00000 00 0000 000 | 99 165 770,0 |
| Оешмалар табышына салым | 1 01 01000 00 0000 110 | 59 400 000,0 |
| Физик затлар керемнәренә салым | 1 01 02000 01 0000 110 | 39 765 770,0 |
| Россия Федерациясе территориясендә реализацияләнә торган товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) салымнар | 1 03 00000 00 0000 000 | 14 307 487,0 |
| Россия Федерациясе территориясендә житештерелә торган акцизлы товарларга (продукциягә) акцизлар | 1 03 02000 01 0000 110 | 14 307 487,0 |
| Җыелма керемгә салымнар | 1 05 00000 00 0000 000 | 3 512 220,7 |
| Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллануга бәйле рәвештә алына торган салым | 1 05 01000 00 0000 110 | 3 512 220,7 |
| Мөлкәткә салымнар | 1 06 00000 00 0000 000 | 23 105 856,0 |
| Оешмалар мөлкәтенә салым | 1 06 02000 02 0000 110 | 19 550 000,0 |
| Транспорт салымы | 1 06 04000 02 0000 110 | 3 550 000,0 |
| Уен бизнесына салым | 1 06 05000 02 0000 110 | 5 856,0 |
| Табигать ресурсларыннан файдаланган өчен салымнар, җыемнар һәм даими түләүләр | 1 07 00000 00 0000 000 | 65 700,0 |
| Файдалы казылмалар чыгаруга салым | 1 07 01000 01 0000 110 | 64 700,0 |
| Хайваннар дөньясы объектларыннан файдаланган һәм су биологик ресурслары объектларыннан файдаланган өчен җыемнар | 1 07 04000 01 0000 110 | 1 000,0 |
| Дәүләт пошлинасы | 1 08 00000 00 0000 000 | 476 060,0 |

| Исеме | Керем коды | Суммасы |
|---|---|---|
| Дәүләт теркәвенә алган өчен, шулай ук бүтән юридик әһәмиятле гамәлләрне башкарган өчен дәүләт пошлинасы | 1 08 07000 01 0000 110 | 476 060,0 |
| Юкка чыгарылган салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар һәм яңадан исәпләүләр | 1 09 00000 00 0000 000 | 10 000,0 |
| Дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге мөлкәттән файдаланудан керемнәр | 1 11 00000 00 0000 000 | 437 686,0 |
| Хуҗалык ширкәтләренең һәм җәмгыятьләренең устав (җыелма) капиталларындагы өлешләренә туры килә торган табыш яисә Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының яисә муниципаль берәмлекләрнең акцияләре буенча дивидендлар рәвешендәге керемнәр | 1 11 01000 00 0000 120 | 108 429,0 |
| Ил эчендә бюджет кредитлары бирүдән алынган процентлар | 1 11 03000 00 0000 120 | 128 457,0 |
| Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне (бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш) түләүле файдалануга тапшырган өчен аренда түләве йә башка түләү рәвешендә алына торган керемнәр | 1 11 05000 00 0000 120 | 101 863,0 |
| Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләрдән түләүләр | 1 11 07000 00 0000 120 | 45 417,0 |
| Дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге мөлкәтне (бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш) залогка, ышанычлы идарәгә тапшырудан алына торган акчалар | 1 11 08000 00 0000 120 | 53 520,0 |
| Табигать ресурсларыннан файдаланганда түләүләр | 1 12 00000 00 0000 000 | 337 364,9 |
| Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләү | 1 12 01000 01 0000 120 | 314 728,0 |
| Җир асты байлыкларыннан файдаланганда түләүләр | 1 12 02000 00 0000 120 | 18 027,3 |
| Урманнардан файдаланган өчен түләү | 1 12 04000 00 0000 120 | 4 609,6 |
| Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән (эшләр башкарудан) һәм дәүләт чыгымнарын компенсацияләүдән керемнәр | 1 13 00000 00 0000 000 | 1 200 685,3 |
| Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән (эшләр башкарудан) керемнәр | 1 13 01000 00 0000 130 | 119 554,3 |
| Дәүләт чыгымнарын компенсацияләүдән керемнәр | 1 13 02000 00 0000 130 | 1 081 131,0 |
| Матди һәм матди булмаган активларны сатудан керемнәр | 1 14 00000 00 0000 000 | 264 146,0 |
| Дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге мөлкәтне (бюджет һәм автоном учреждениеләрнең күчемле мөлкәтеннән, шулай ук дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш) реализацияләүдән керемнәр | 1 14 02000 00 0000 000 | 192 146,0 |



| Исеме | Керем коды | Суммасы |
|---|---|---|
| Дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен сатудан керемнәр | 1 14 06000 00 0000 430 | 72 000,0 |
| Административ түләүләр һәм җыемнар | 1 15 00000 00 0000 000 | 1 973,8 |
| Дәүләт һәм муниципаль органнар (оешмалар) тарафыннан аерым функцияләр башкарган өчен алына торган түләүләр | 1 15 02000 00 0000 140 | 1 973,8 |
| Штрафлар, санкцияләр, зыянны каплау | 1 16 00000 00 0000 000 | 3 286 348,2 |
| Товар базарларында конкуренция, финанс хезмәтләре күрсәтү базарында конкуренцияне яклау өлкәсендә монополиягә каршы законнарны, табигый монополияләр турындагы законнарны һәм бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу турындагы законнарны бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 02000 00 0000 140 | 2 300,0 |
| Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарны бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 03000 00 0000 140 | 30,0 |
| Җинаятьләр кылуда һәм мөлкәткә зыян китерүдә гаепле затлардан алына торган акчалата түләтүләр (штрафлар) һәм башка суммалар | 1 16 21000 00 0000 140 | 1,2 |
| Иминият очраклары барлыкка килгәндә зыян каплаудан керемнәр | 1 16 23000 00 0000 140 | 148,0 |
| Җир асты байлыклары турында, махсус сакланылучы табигать территорияләре турында, хайваннар дөньясын саклау һәм алардан файдалану турында, экологик экспертиза турында, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә, балыкчылык һәм су биологик ресурсларын саклау турында, җир законнары, урман законнары, су законнары турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 25000 00 0000 140 | 977,0 |
| Реклама турындагы законнарны бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 26000 01 0000 140 | 1 500,0 |
| Янгын куркынычсызлыгы турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 27000 01 0000 140 | 20 000,0 |
| Юл хәрәкәте өлкәсендә хокук бозулар өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 30000 01 0000 140 | 3 250 000,0 |
| Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнарын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 33000 00 000 140 | 2 445,0 |
| Әйләнә-тирә мохиткә китергән зыянны түләтү турындагы дәгъвалар буенча суммалар | 1 16 35000 00 0000 140 | 947,0 |
| Зыянны каплауга акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) һәм башка суммалардан бүтән кертемнәр | 1 16 90000 00 0000 140 | 8 000,0 |

| Исеме | Керем коды | Суммасы |
|---|---|---|
| Салым булмаган башка керемнәр | 1 17 00000 00 0000 000 | 400 522,0 |
| Салым булмаган башка керемнәр | 1 17 05000 00 0000 180 | 400 522,0 |
| Кире кайтарылмый торган кертемнәр | 2 00 00000 00 0000 000 | 26 303 524,4 |
| Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан керүче кире кайтарылмый торган кертемнәр | 2 02 00000 00 0000 000 | 25 005 655,9 |
| Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләре бюджетларына дотацияләр | 2 02 01000 00 0000 151 | 1 429 261,9 |
| Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына субсидияләр (бюджетара субсидияләр) | 2 02 02000 00 0000 151 | 10 782 526,0 |
| Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләр бюджетларына субвенцияләр | 2 02 03000 00 0000 151 | 7 909 431,6 |
| Башка бюджетара трансфертлар | 2 02 04000 00 0000 151 | 4 884 373,2 |
| Бюджет системасының башка бюджетларыннан керүче кире кайтарылмый торган башка кертемнәр | 2 02 09000 00 0000 151 | 63,2 |
| Дәүләт (муниципаль) оешмаларыннан керүче кире кайтарылмый торган кертемнәр | 2 03 00000 00 0000 000 | 1 270 032,2 |
| Кире кайтарылмый торган башка кертемнәр | 2 07 00000 00 0000 000 | 62 430,0 |
| Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына кире кайтарылмый торган башка кертемнәр | 2 07 02000 02 0000 180 | 62 430,0 |
| Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары һәм оешмалар тарафыннан узган еллардагы субсидияләрнең, субвенцияләрнең һәм максатчан билгеләнеше булган бүтән бюджетара трансфертларның калган өлешләрен кайтарудан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәре | 2 18 00000 00 0000 000 | 23 320,0 |
| Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары тарафыннан узган еллардагы субсидияләрнең, субвенцияләрнең һәм максатчан билгеләнеше булган бүтән бюджетара трансфертларның калган өлешләрен кайтарудан Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары керемнәре | 2 18 02000 02 0000 151 | 23 320,0 |
| Узган еллардагы максатчан билгеләнешкә ия субсидияләрнең, субвенцияләрнең һәм башка бюджетара трансфертларның калган өлешләрен кайтару | 2 19 00000 00 0000 000 | -57 913,7 |
| Узган еллардагы Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан максатчан билгеләнешкә ия субсидияләрнең, субвенцияләрнең һәм башка бюджетара трансфертларның калган өлешләрен кайтару | 2 19 02000 02 0000 151 | -57 913,7 |
| Барлык керемнәр | | 172 875 344,3»; |



14) 6 нчы кушымтада:

а)

| | | |
|---|---|---|
| «000 | 2 02 02198 02 0000 151 | Хуҗалык итүнең кече формалары алган озак сроклы, урта сроклы һәм кыска сроклы кредитлар буенча процент ставкасы өлешен каплауга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» |

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «000 | 2 02 02199 02 0000 151 | Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән үзләре файдалана торган җир кишәрлекләрен милек итеп рәсмиләштергәндә крестьян (фермер) хуҗалыкларының, индивидуаль эшкуарларны да кертеп, чыгымнар өлешен каплауга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр»; |

б)

| | | |
|---|---|---|
| «000 | 2 02 02203 02 0000 151 | Дуңгыз ите, кош ите һәм йомырка җитештерүне гамәлгә ашыручы авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә сатып алынган азыклар кыйммәтләнүгә бәйле рәвештә ярдәм итүгә бәйле чыгымнарын каплауга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» |

юлын төшереп калдырырга;

в)

| | | |
|---|---|---|
| «000 | 2 02 02205 02 0000 151 | Авыл хуҗалыгы производствосын техник һәм технологик модернизацияләүне тәэмин итүгә авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләр чыгымнары өлешен каплауга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» |

юлын төшереп калдырырга;

г)

| | | |
|---|---|---|
| «000 | 2 02 02220 02 0000 151 | «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын этаплап кертү чараларын гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» |

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «000 | 2 02 02240 02 0000 151 | Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә Россия Федерациясе субъектлары хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр |
| 000 | 2 02 02241 02 0000 151 | Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминиятенең нигез программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәткәндә барлыкка килә торган чыгымнарны финанслашу максатларында Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр |

000 2 02 02255 02 0000 151 Троллейбус һәм трамвай вагоннары сатып алуга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр»;

д)

«000 2 02 04033 02 0000 151 «Россиянең иң төзек шәһәр (авыл) җирлеге» исеменә бөтенроссия конкурсында җиңүчеләрне бүләкләүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

«000 2 02 04034 02 0001 151 Россия Федерациясе субъектларының сәламәтлек саклауны модернизацияләү буенча региональ программаларын медицина учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту өлешендә гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар»;

е)

«000 2 02 04044 02 0000 151 Россия Федерациясендә 2018 елда футбол буенча дөнья чемпионатын әзерләү һәм үткәрү буенча стадионнар төзү яисә реконструкцияләү максатларында проектлау эшләренә бәйле чараларны гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар»

юлын төшереп калдырырга;

ж)

«000 2 02 04076 02 0000 151 Балаларны ял иттерү һәм сәламәтләндерү буенча Кырым Республикасында һәм Севастополь шәһәрендә урнашкан оешмаларда аларның ял итүенә һәм сәламәтләнүенә бәйле чараларны финанс белән тәэмин итүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар»

юлын төшереп калдырырга;

з)

«000 2 02 04081 02 0000 151 Украина территориясеннән китәргә мәҗбүр булган һәм вакытлыча тору пунктларында урнашкан затларга вакытлыча социаль-көнкүреш шартларын финанс белән тәэмин итү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:



«000 2 02 04087 02 0000 151 Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары буйсынуындагы медицина оешмалары тарафыннан 2014 – 2015 елларда Украина гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга медицина ярдәме күрсәтүгә, шулай ук күрсәтелгән затларга эпидемия күрсәткечләре буенча профилактик прививкалар календарена кертелгән профилактик прививкалар ясауга бәйле чыгымнарны компенсацияләү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар»;

и)

«000 2 02 04091 02 0000 151 Юллар эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

«000 2 02 04095 02 0000 151 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары буенча юллар хуҗалыгы өлкәсендә региональ программалар чараларын гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар

000 2 02 04097 02 0000 151 Россия Федерациясенең аерым регионнарында табигый характердагы гадәттән тыш хәлләр аркасында килгән зыянны авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә компенсацияләүне гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар»;

15)7 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына 7 нче кушымта

Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеге

| Бюджет классификациясе коды | | Исеме |
|---|---|---|
| баш администратор | Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары | |
| 711 | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы | |

| Бюджет классификациясе коды | | Исеме |
|---|---|---|
| баш администратор | Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары | |
| 711 | 01 03 01 00 02 0000 710 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына кредитлар алу |
| 711 | 01 03 01 00 02 0000 810 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган кредитларны Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан каплау |
| 711 | 01 05 02 01 02 0000 510 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының калган бүтән акчаларын арттыру |
| 711 | 01 05 02 01 02 0000 610 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының калган бүтән акчаларын киметү |
| 711 | 01 06 04 01 02 0000 810 | Россия Федерациясе субъектлары дәүләт гарантияләрен гарант тарафыннан үтәү гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукын барлыкка китергән йә бенефициарның принципалга карата таләбе хокуклары гарантка биреп торылган очракта, Россия Федерациясе субъекты дәүләт гарантияләрен Россия Федерациясе валютасында үтәү |
| 711 | 01 06 04 02 02 0000 820 | Россия Федерациясе субъекты дәүләт гарантияләрен гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән очракта, максатчан чит ил кредитларыннан (хисаплашулардан) файдалану кысаларында Россия Федерациясенә бирелгән Россия Федерациясе субъекты дәүләт гарантияләрен чит ил валютасында үтәү |
| 711 | 01 06 05 01 02 0000 640 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында юридик затларга бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару |
| 711 | 01 06 05 02 02 0000 540 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына бюджет кредитлары бирү |
| 711 | 01 06 08 00 02 0000 640 | Ил эчендә Россия Федерациясе субъектлары бюджетыннан бирелгән башка бюджет кредитларын (ссудаларын) кире кайтару |
| 720 | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | |
| 720 | 01 06 01 00 02 0000 630 | Россия Федерациясе субъектлары милкендәге акцияләрне һәм капиталда катнашуларның башка рәвешләрен сатудан кергән акчалар |
| 000 | Барлык администраторларга беркетелә торган чыганаклар | |
| 000 | 01 05 02 01 02 0000 510 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының калган бүтән акчаларын арттыру |
| 000 | 01 05 02 01 02 0000 610 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының калган бүтән акчаларын киметү |



| Бюджет классификациясе коды | | Исеме |
|---|---|---|
| баш администратор | Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары | |
| 000 | 01 06 03 00 02 0000 171 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары акчалары буенча курс аермасы»; |

16) 8 нче кушымтада:

а) 1 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 нче таблица

## 2015 елга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары ведомство структурасы

(мең сумнарда)

| Исеме | КВСР | Рз | ПР | ЦСР | ВР | Суммасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Экология һәм табигать байлыклары министрлыгы | 701 | | | | | 414 790,4 |
| Гомумдәүләт мәсьәләләре | 701 | 01 | | | | 206,9 |
| Башка гомумдәүләт мәсьәләләре | 701 | 01 | 13 | | | 206,9 |
| Чыгымнарның программада каралмаган юнәлешләре | 701 | 01 | 13 | 99 0 0000 | | 206,9 |
| «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен мәҗбүри дәүләт иминләштерүе турында» 2012 елның 14 июлендәге 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру | 701 | 01 | 13 | 99 0 9231 | | 206,9 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 701 | 01 | 13 | 99 0 9231 | 200 | 206,9 |
| Милли икътисад | 701 | 04 | | | | 110 238,0 |
| Минерал-чимал базасын торгызу | 701 | 04 | 04 | | | 50 000,0 |
| «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» дәүләт программасы | 701 | 04 | 04 | 09 0 0000 | | 50 000,0 |
| «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә дәүләт идарәсе» ярдәмче программасы | 701 | 04 | 04 | 09 3 0000 | | 50 000,0 |
| Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү һәм минерал-чимал базасын торгызу гамәлләре | 701 | 04 | 04 | 09 3 8510 | | 50 000,0 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү | 701 | 04 | 04 | 09 3 8510 | 200 | 50 000,0 |
| Су хуҗалыгы | 701 | 04 | 06 | | | 60 238,0 |

| Исеме | КВСР | Рз | ПР | ЦСР | ВР | Суммасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» дәүләт программасы | 701 | 04 | 06 | 09 0 0000 | | 60 238,0 |
| «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы су хуҗалыгы комплексын үстерү» ярдәмче программасы | 701 | 04 | 06 | 09 4 0000 | | 60 238,0 |
| Су мөнәсәбәтләре өлкәсендә аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыру | 701 | 04 | 06 | 09 4 5128 | | 31 742,0 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 701 | 04 | 06 | 09 4 5128 | 200 | 31 742,0 |
| Су объектларын торгызу һәм экологик реабилитацияләү | 701 | 04 | 06 | 09 4 9046 | | 10 000,0 |
| Бюджетара трансфертлар | 701 | 04 | 06 | 09 4 9046 | 500 | 10 000,0 |
| Су объектларын саклау өлкәсендә башка гамәлләр | 701 | 04 | 06 | 09 4 9048 | | 18 496,0 |
| Бюджетара трансфертлар | 701 | 04 | 06 | 09 4 9048 | 500 | 18 496,0 |
| Әйләнә-тирә мохитне саклау | 701 | 06 | | | | 304 058,8 |
| Үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектларын, аларның яшәү тирәлеген саклау | 701 | 06 | 03 | | | 196 724,7 |
| «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» дәүләт программасы | 701 | 06 | 03 | 09 0 0000 | | 196 324,7 |
| «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохите сыйфатын җайга салу» ярдәмче программасы | 701 | 06 | 03 | 09 1 0000 | | 56 156,2 |
| Әйләнә-тирә мохитнең сыйфатын җайга салу чаралары | 701 | 06 | 03 | 09 1 1910 | | 43 211,1 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 701 | 06 | 03 | 09 1 1910 | 200 | 43 211,1 |
| Экологик белем бирү һәм агарту чаралары | 701 | 06 | 03 | 09 1 1970 | | 12 945,1 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 701 | 06 | 03 | 09 1 1970 | 200 | 12 945,1 |
| «2014 – 2015 елларга Татарстан Республикасында җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә дәүләт идарәсе» ярдәмче программасы | 701 | 06 | 03 | 09 2 0000 | | 71 156,3 |
| Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру | 701 | 06 | 03 | 09 2 1920 | | 71 156,3 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 701 | 06 | 03 | 09 2 1920 | 200 | 10 900,0 |
| Бюджетара трансфертлар | 701 | 06 | 03 | 09 2 1920 | 500 | 60 256,3 |



| Исеме | КВСР | Рз | ПР | ЦСР | ВР | Суммасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «2014 – 2020 елларга әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендәге хезмәтләр эшчәнлеген координацияләү» ярдәмче программасы | 701 | 06 | 03 | 09 7 0000 | | 69 012,2 |
| Табигатьне саклау учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итү | 701 | 06 | 03 | 09 7 1991 | | 69 012,2 |
| Дәүләт (муниципаль) органнары, казна учреждениеләре, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары тарафыннан функцияләр башкаруны тәэмин итү максатларында персоналга түләү чыгымнары | 701 | 06 | 03 | 09 7 1991 | 100 | 36 620,3 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 701 | 06 | 03 | 09 7 1991 | 200 | 28 921,9 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 701 | 06 | 03 | 09 7 1991 | 800 | 3 470,0 |
| «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасын икътисадый үстерү һәм аның инновацион икътисады» дәүләт программасы | 701 | 06 | 03 | 11 0 0000 | | 400,0 |
| «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм» ярдәмче программасы | 701 | 06 | 03 | 11 3 0000 | | 400,0 |
| Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге эшчәнлеккә ярдәм | 701 | 06 | 03 | 11 3 1001 | | 400,0 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 701 | 06 | 03 | 11 3 1001 | 200 | 400,0 |
| Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә башка мәсьәләләр | 701 | 06 | 05 | | | 107 334,1 |
| «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» дәүләт программасы | 701 | 06 | 05 | 09 0 0000 | | 107 334,1 |
| «2014 – 2020 елларга әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендәге хезмәтләр эшчәнлеген координацияләү» ярдәмче программасы | 701 | 06 | 05 | 09 7 0000 | | 107 334,1 |
| Үзәк аппарат | 701 | 06 | 05 | 09 7 0204 | | 106 334,1 |
| Дәүләт (муниципаль) органнары, казна учреждениеләре, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары тарафыннан функцияләр башкаруны тәэмин итү максатларында персоналга түләү чыгымнары | 701 | 06 | 05 | 09 7 0204 | 100 | 86 332,8 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 701 | 06 | 05 | 09 7 0204 | 200 | 19 978,3 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 701 | 06 | 05 | 09 7 0204 | 800 | 23,0 |
| Оешмалар мөлкәтенә салым һәм җир салымы түләү | 701 | 06 | 05 | 09 7 0295 | | 1 000,0 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 701 | 06 | 05 | 09 7 0295 | 800 | 1 000,0 |

| Исеме | КВСР | Рз | ПР | ЦСР | ВР | Суммасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Социаль сәясәт | 701 | 10 | | | | 286,7 |
| Пенсия белән тәэмин итү | 701 | 10 | 01 | | | 286,7 |
| 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасы | 701 | 10 | 01 | 03 0 0000 | | 286,7 |
| 2014 – 2020 елларга «Өлкән яшьтәге гражданнарның тормыш сыйфатын яхшырту» ярдәмче программасы | 701 | 10 | 01 | 03 2 0000 | | 286,7 |
| Пенсияләргә өстәмәләр, өстәмә рәвештә пенсия белән тәэмин итү | 701 | 10 | 01 | 03 2 4910 | | 286,7 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 701 | 10 | 01 | 03 2 4910 | 300 | 286,7 |
| Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | 702 | | | | | 1 190 816,8 |
| Гомумдәүләт мәсьәләләре | 702 | 01 | | | | 331 908,0 |
| Фундаменталь тикшеренүләр | 702 | 01 | 10 | | | 16 088,4 |
| «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасы | 702 | 01 | 10 | 02 0 0000 | | 16 088,4 |
| «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында фәнне һәм фәнни тикшеренүләрне үстерү» ярдәмче программасы | 702 | 01 | 10 | 02 6 0000 | | 16 088,4 |
| Фундаменталь тикшеренүләр үткәрә торган оешмаларга ярдәм | 702 | 01 | 10 | 02 6 0610 | | 16 088,4 |
| Бюджет учреждениеләренә, автоном учреждениеләргә һәм коммерциягә карамаган башка оешмаларга субсидияләр бирү | 702 | 01 | 10 | 02 6 0610 | 600 | 16 088,4 |
| Башка гомумдәүләт мәсьәләләре | 702 | 01 | 13 | | | 315 819,6 |
| «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасын икътисадый үстерү һәм аның инновацион икътисады» дәүләт программасы | 702 | 01 | 13 | 11 0 0000 | | 315 642,9 |
| «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт икътисадый сәясәтен камилләштерү» ярдәмче программасы | 702 | 01 | 13 | 11 1 0000 | | 315 642,9 |
| Үзәк аппарат | 702 | 01 | 13 | 11 1 0204 | | 84 368,0 |
| Дәүләт (муниципаль) органнары, казна учреждениеләре, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары тарафыннан функцияләр башкаруны тәэмин итү максатларында персоналга түләү чыгымнары | 702 | 01 | 13 | 11 1 0204 | 100 | 68 168,5 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 702 | 01 | 13 | 11 1 0204 | 200 | 16 129,5 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 702 | 01 | 13 | 11 1 0204 | 800 | 70,0 |
| Оешмалар мөлкәтенә салым һәм җир салымы түләү | 702 | 01 | 13 | 11 1 0295 | | 659,7 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 702 | 01 | 13 | 11 1 0295 | 800 | 659,7 |
| Татарстан Республикасы территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чаралар | 702 | 01 | 13 | 11 1 2518 | | 67 372,5 |



| Исеме | КВСР | Рз | ПР | ЦСР | ВР | Суммасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Бюджетара трансфертлар | 702 | 01 | 13 | 11 1 2518 | 500 | 67 372,5 |
| Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре челтәрен булдыру һәм үстерү | 702 | 01 | 13 | 11 1 5392 | | 27 162,3 |
| Бюджет учреждениеләренә, автоном учреждениеләргә һәм коммерциягә карамаган башка оешмаларга субсидияләр бирү | 702 | 01 | 13 | 11 1 5392 | 600 | 27 162,3 |
| Башка түләүләр | 702 | 01 | 13 | 11 1 9235 | | 36 181,1 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 702 | 01 | 13 | 11 1 9235 | 200 | 26 279,0 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 702 | 01 | 13 | 11 1 9235 | 800 | 9 902,1 |
| Ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлеген тәэмин итү | 702 | 01 | 13 | 11 1 9299 | | 99 899,3 |
| Бюджет учреждениеләренә, автоном учреждениеләргә һәм коммерциягә карамаган башка оешмаларга субсидияләр бирү | 702 | 01 | 13 | 11 1 9299 | 600 | 99 899,3 |
| Чыгымнарның программада каралмаган юнәлешләре | 702 | 01 | 13 | 99 0 0000 | | 176,7 |
| «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен мәҗбүри дәүләт иминләштерүе турында» 2012 елның 14 июлендәге 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру | 702 | 01 | 13 | 99 0 9231 | | 176,7 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 702 | 01 | 13 | 99 0 9231 | 200 | 176,7 |
| Милли икътисад | 702 | 04 | | | | 854 321,2 |
| Милли икътисад өлкәсендә башка мәсьәләләр | 702 | 04 | 12 | | | 854 321,2 |
| «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасын икътисадый үстерү һәм аның инновацион икътисады» дәүләт программасы | 702 | 04 | 12 | 11 0 0000 | | 854 321,2 |
| «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» ярдәмче программасы | 702 | 04 | 12 | 11 2 0000 | | 854 321,2 |
| Крестьян (фермер) хуҗалыкларын да кертеп, кече һәм урта эшкуарлыкка субсидияләр исәбеннән дәүләт ярдәме чаралары | 702 | 04 | 12 | 11 2 5064 | | 437 495,3 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 702 | 04 | 12 | 11 2 5064 | 200 | 437 142,0 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 702 | 04 | 12 | 11 2 5064 | 800 | 353,3 |
| Крестьян (фермер) хуҗалыкларын да кертеп, кече һәм урта эшкуарлыкка дәүләт ярдәме чаралары | 702 | 04 | 12 | 11 2 6064 | | 416 825,9 |

| Исеме | КВСР | Рз | ПР | ЦСР | ВР | Суммасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
о) татарча текстта 17 пунктның беренче абзацындагы беренче җөмлә үзгәрми, икенче җөмләдә «бюджет тәэмин ителешен» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителешен» сүзләренә алмаштырырга;

п) 19 пунктта:

беренче абзацта «бюджет тәэмин ителешен» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителешен» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә пропорциональ тигезләү ысулын кулланып бүленә торган ФФПСП өлеше» сүзләрен «пропорциональ тигезләү ысулын кулланып бүленә торган ФФПСП дотацияләре өлеше» сүзләренә алмаштырырга, татарча текстта абзацның калган өлешләре үзгәрми;

алтынчы абзацта «авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә ФФПСП күләме» сүзләрен «ФФПСП дотацияләре күләме» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта тиешле килештәге «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен тиешле килештәге «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта тиешле килештәге «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен тиешле килештәге «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә алмаштырырга;

р) 20 пунктта:

беренче абзацта тиешле килештәге «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен тиешле килештәге «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта тиешле килештәге «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен тиешле килештәге «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «бюджет тәэмин ителешен» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителешен» сүзләренә алмаштырырга;

с) 22 пунктның беренче абзацында «авыл җирлеге» сүзләрен «і-авыл җирлеге» сүзләренә, тиешле килештәге «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен тиешле килештәге «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә алмаштырырга;

т) 23 пунктта:

беренче абзацта ике җирдә «акчаларының» сүзен «дотацияләренең» сүзенә, тиешле килештәге «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен тиешле килештәге «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта тиешле килештәге «бюджет тәэмин ителе-

ше» сүзләрен тиешле килештәге «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә, «акчаларының» сүзен «дотацияләренең» сүзенә алмаштырырга;

бишенче абзацта тиешле килештәге «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен тиешле килештәге «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә, «акчаларын» сүзен «дотацияләрен» сүзенә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «ФФПСП акчалары өлеше күләме» сүзләрен «ФФПСП дотацияләренең беренче өлеше күләме» сүзләренә, «беренче этапта бүленгән» сүзләрен «, хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, авыл җирлекләре арасында бүленгән» сүзләренә алмаштырырга;

у) 24 пунктта:

бишенче абзацта «бюджет тәэмин ителешен» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителешен» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта ике җирдә «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә, «акчаларының» сүзен «дотацияләренең» сүзенә алмаштырырга;

ф) 25 пунктның беренче абзацында «Авыл җирлегенең» сүзләрен «I-авыл җирлегенең» сүзләренә алмаштырырга;

4) 5 нче кушымтада:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр (алга таба шулай ук – дотацияләр) муниципаль районнар (шәһәр округлары) арасында, хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, муниципаль районнарның (шәһәр округларының) хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсен һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) буенча шундый ук уртача күрсәткечне чагыштыру нигезендә бүленә.»;

б) 3 пунктның беренче абзацында «ФФПМР акчалары» сүзләрен «Дотацияләр» сүзенә, «Фонд акчаларының» сүзләрен «Дотацияләрнең» сүзенә, «бюджет тәэмин ителешен» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителешен» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 пунктта «ФФПМРның» сүзен «Дотацияләрнең» сүзенә алмаштырырга;

г) 5 пунктта:

беренче абзацта «ФФПМР акчаларының» сүзен «Дотацияләрнең» сүзенә, «бюджет тәэмин ителешен» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителешен» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$$D_1^i = d_{\text{ПП}} \times V_D \times \frac{\text{Н}^i}{\text{Н}},$$»;

бишенче абзацта «ФФПМРның өлеше» сүзләрен «дотацияләр өлеше» сүзләренә алмаштырырга, татарча текстта абзацның башка өлешләре үзгәрми;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$V_D$ – дотацияләрнең гомуми күләме;»;

җиденче абзацта «бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә» сүзләренә алмаштырырга;

д) 6 пунктта:

беренче абзацта «бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә» сүзләренә алмаштырырга;

е) 7 пунктның җиденче абзацында «муниципаль районнар» сүзләрен «Татарстан Республикасында муниципаль районнар» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 8 пунктта «Муниципаль районнарга» сүзләрен «I-муниципаль районнарга» сүзләренә, тиешле килештәге «бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә» сүзләрен тиешле килештәге «хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә» сүзләренә алмаштырырга;

з) 9 пунктта:

беренче абзацта ике җирдә «ФФПМР акчаларының» сүзләрен «Дотацияләрнең» сүзенә, «бюджет тәэмин ителешенә» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителешенә» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителешенә» сүзләренә, «ФФПМР акчаларының» сүзләрен «дотацияләрнең» сүзенә алмаштырырга;

бишенче абзацта «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителешенә» сүзләренә, «ФФПМР акчаларын» сүзләрен «дотацияләрне» сүзенә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «ФФПМР акчаларының беренче этапта бүленгән өлеше» сүзләрен «дотацияләрнең беренче өлеше» сүзләренә алмаштырырга;

и) 10 пунктта:

беренча абзацта «ФФПМР акчаларының» сүзләрен «Дотацияләрнең» сүзенә алмаштырырга;

бишенче абзацта «бюджет тәэмин ителешенең» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителешенең» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә, «ФФПМР акчаларының» сүзләрен «дотацияләрнең» сүзенә алмаштырырга;

9) 12 нче кушымтада:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә муниципаль район бюджетыннан бирелә торган дотацияләр (алга таба шулай ук – дотацияләр) муниципаль район составына керүче шәһәр, авыл җирлекләре арасында шәһәр, авыл җирлекләренең хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсен һәм әлеге муниципаль районның шәһәр, авыл җирлекләре буенча шундый ук уртача күрсәткечне чагыштыру нигезендә бүленә, моңа әлеге Кодексның $44^1$ статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән тәртиптә бирелә торган дотацияләр керми.»;

4 пунктның беренче абзацында «РФФПП акчалары» сүзләрен «Дотацияләр» сүзенә, «Фонд акчаларының» сүзләрен «Дотацияләрнең» сүзенә, «бюджет тәэмин ителешен» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителешен» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта «РФФППның теге яки бу ысул белән бүленә торган өлешләре» сүзләрен «Дотацияләрнең теге яки бу ысул белән бүленә торган өлешләре» сүзләренә алмаштырырга;

г) 6 пунктта:

беренче абзацта «ФФПМР акчаларының» сүзләрен «Дотацияләрнең» сүзенә, «бюджет тәэмин ителешен» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителешен» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$D_1^j = d_{\text{ПП}} \times V_D \times \dfrac{\text{Н}^j}{\text{Н}},$»;

бишенче абзацта «РФФППның» сүзен «дотацияләрнең» сүзенә алмаштырырга, татарча текстта абзацның калган өлешләре үзгәрми;



алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$V_D$ – дотацияләрнең гомуми күләме;»;

җиденче абзацта тиешле килештәге «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен тиешле килештәге «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта тиешле килештәге «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен тиешле килештәге «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә алмаштырырга;

д) 7 пунктта:

беренче абзацта тиешле килештәге «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен тиешле килештәге «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта тиешле килештәге «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен тиешле килештәге «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «бюджеттан тәэмин ителешен» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителешен» сүзләренә алмаштырырга;

е) 9 пунктта «ирешү өчен» сүзләрен «i-җирлекләрнең ирешүе өчен» сүзләренә, тиешле килештәге «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен тиешле килештәге «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 10 пунктта:

беренче абзацта тиешле килештәге «РФФПП акчаларының» сүзләрен тиешле килештәге «дотацияләрнең» сүзенә, «бюджет тәэмин ителешенә» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителешенә» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә, «РФФПП акчаларының» сүзләрен «дотацияләрнең» сүзенә алмаштырырга;

бишенче абзацта «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә, «РФФПП акчаларын» сүзләрен «дотацияләрне» сүзенә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «РФФПП акчаларының беренче этапта бүленгән өлеше» сүзләрен «дотацияләрнең беренче өлеше» сүзләренә алмаштырырга;

з) 11 пунктта:

беренче абзацта «РФФПП акчаларының» сүзләрен «Дотацияләрнең» сүзенә алмаштырырга;

бишенче абзацта «бюджет тәэмин ителешенең» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителешенең» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә, «РФФПП акчаларының» сүзләрен «дотацияләрнең» сүзенә алмаштырырга.

**2 статья**

«Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына җирлекләрнең региональ финанс ярдәме фондыннан шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен тапшыру турында» 2005 елның 22 декабрендәге 132-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (II өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 10; 2014, № 12 (III өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемдә «җирлекләрнең региональ финанс ярдәме фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән» сүзләренә алмаштырырга;

2) преамбулада «җирлекләрнең региональ финанс ярдәме фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына» сүзләренә алмаштырырга;

3) 1 статьяда «җирлекләрнең региональ финанс ярдәме фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән» сүзләренә, «алга таба» сүзләрен «алга таба шулай ук» сүзләренә алмаштырырга;

4) татарча текстта 5 статьяның икенче өлеше үзгәрми;

5) 1 нче кушымтада:

а)

«Муниципаль районнарның җирле
үзидарә органнарына җирлекләрнең
региональ финанс ярдәме фондыннан
шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр
исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы
дәүләт вәкаләтләрен тапшыру турында»
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта»

сүзләрен



«Муниципаль районнарның җирле
үзидарә органнарына Татарстан Республикасы бюджеты
акчалары исәбеннән шәһәр, авыл җирлекләре
бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча
Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен тапшыру
турында» Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта»

сүзләренә алмаштырырга;

б) исемдә «вәкаләтләрен» сүзен «буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен» сүзләренә алмаштырырга, «шәһәр» сүзе алдыннан «Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән» сүзләрен өстәргә;

в) 1 пунктта «вәкаләтләрен» сүзен «буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен» сүзләренә алмаштырырга;

г) 3 пунктта:

беренче абзацта «вәкаләтләрен» сүзен «буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «вәкаләтләрен» сүзен «буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «вәкаләтләрен» сүзен «буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «вәкаләтләрен» сүзен «буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен» сүзләренә алмаштырырга;

д) 4 пунктта:

беренче абзацта «вәкаләтләрен» сүзен «буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «вәкаләтләрен» сүзен «буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «вәкаләтләрен» сүзен «буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен» сүзләренә алмаштырырга;

е) 5 пунктта:

беренче абзацта «вәкаләтләрне» сүзен «Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «вәкаләтләрне» сүзен «Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «вәкаләтләрне» сүзен «Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен» сүзләренә алмаштырырга;

6) 2 нче кушымтада:
а)

«Муниципаль районнарның җирле
үзидарә органнарына җирлекләрнең
региональ финанс ярдәме фондыннан
шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр
исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы
дәүләт вәкаләтләрен тапшыру турында»
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта»

сүзләрен

«Муниципаль районнарның җирле
үзидарә органнарына Татарстан Республикасы бюджеты
акчалары исәбеннән шәһәр, авыл җирлекләре
бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча
Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен тапшыру
турында» Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта»

сүзләренә алмаштырырга;

б) татарча текстта исем үзгәрми;

в) 1 пунктта:

беренче абзацта «субвенцияләр» сүзен «субвенция» сүзенә, «вәкаләтләрне» сүзен «Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен» сүзләренә, «(алга таба – РФПГП)» сүзләрен «(алга таба шулай ук – РФПГП дотацияләре)» сүзләренә, «акча өлешләре» сүзләрен «дотацияләр өлешләре» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «субвенцияләр» сүзен «субвенция» сүзенә, «вәкаләтләрне» сүзен «Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен» сүзләренә, «(алга таба – РФПСП)» сүзләрен «(алга таба шулай ук – РФПСП дотацияләре)» сүзләренә, «акча өлешләре» сүзләрен «дотацияләр өлешләре» сүзләренә алмаштырырга;

г) 2 пунктта:

беренче абзацта «дотация күләме» сүзләрен «РФПГП дотацияләре күләме» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «j-шәһәр җирлегенә РФПГПдан дотация күләме» сүзләрен «j-шәһәр җирлегенә РФПГП дотацияләре күләме» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «бүленә торган РФПГП күләме» сүзләрен «, РФПГП дотацияләре күләме» сүзләренә алмаштырырга;

д) 3 пунктта:

беренче абзацтагы беренче җөмләдә «Шәһәр җирлекләренең бюджет тәэминителешен тигезләүгә РФПГПдан шәһәр җирлекләренә дотацияләр күләме» сүзләрен «РФПГП дотацияләре күләме» сүзләренә, икенче җөмләдә «бюджет тәэмин ителешен» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителешен» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «i-шәһәр җирлеге өчен, хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә РФПГПдан дотациянең» сүзләрен «i-шәһәр җирлеге өчен, хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, РФПГП дотацияләренең» сүзләренә алмаштырырга;

е) 4 пунктта:

беренче абзацта «бюджет тәэмин ителешен» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителешен» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә пропорциональ тигезләү ысулын кулланып бүленә торган РФПГП өлеше» сүзләрен «РФПГП дотацияләренең пропорциональ тигезләү ысулын кулланып бүленә торган өлеше» сүзләренә алмаштырырга, татарча текстта абзацның калган өлешләре үзгәрми;

алтынчы абзацта «шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә РФПГП күләме» сүзләрен «РФПГП дотацияләре күләме» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта тиешле килештәге «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен тиешле килештәге «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта тиешле килештәге «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен тиешле килештәге «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 5 пунктта:

беренче абзацта тиешле килештәге «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен тиешле килештәге «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта тиешле килештәге «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен тиешле килештәге «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «бюджет тәэмин ителешен» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителешен» сүзләренә алмаштырырга;

з) 6 пунктның беренче абзацында тиешле килештәге «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен тиешле килештәге «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә алмаштырырга, татарча текстта абзацның калган өлешләре үзгәрми;

и) 7 пунктта:

беренче абзацта ике җирдә «РФПГП акчаларының» сүзләрен «РФПГП дотацияләренең» сүзләренә, өч җирдә «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта ике җирдә «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә, «РФПГП акчаларының» сүзләрен «РФПГП дотацияләренең» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта ике җирдә «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә, «РФПГП акчаларын» сүзләрен «РФПГП дотацияләрен» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «өлеше» сүзен «дотацияләренең беренче өлеше» сүзләренә, «беренче этапта бүленгән» сүзләрен «, хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, шәһәр җирлекләре арасында бүленгән торган» сүзләренә алмаштырырга;

к) 8 пунктта:

бишенче абзацта «бюджет тәэмин ителешен» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителешен» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта ике җирдә «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә, «акчаларының» сүзен «дотацияләренең» сүзенә алмаштырырга;

л) 9 пунктның беренче абзацында «Шәһәр җирлегенең» сүзләрен «I-шәһәр җирлегенең» сүзләренә алмаштырырга;

м) 10 пунктта:

беренче абзацта «дотация күләме» сүзләрен «РФПГП дотацияләре күләме» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «j-шәһәр җирлегенә РФПСПдан дотация күләме» сүзләрен «j- авыл җирлегенә РФПСП дотацияләре күләме» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «бүленә торган РФПСП күләме» сүзләрен «, РФПСП дотацияләре күләме» сүзләренә алмаштырырга;

н) 11 пунктта:

беренче абзацтагы беренче җөмләдә «Авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә РФПСПдан авыл җирлекләренә дотация күләме» сүзләрен «РФПСП дотацияләре күләме» сүзләренә, икенче җөмләдә «бюджет тәэмин ителешен» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителешен» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә РФПГПдан дотациянең» сүзләрен «РФПСП дотацияләренең» сүзләренә алмаштырырга;



о) 12 пунктта:

беренче абзацта «бюджет тәэмин ителешен» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителешен» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә пропорциональ тигезләү ысулын кулланып бүленә торган РФПСП өлеше» сүзләрен «РФПСП дотацияләренең пропорциональ тигезләү ысулын кулланып бүленә торган өлеше» сүзләренә алмаштырырга, татарча текстта абзацның калган өлешләре үзгәрми;

алтынчы абзацта «авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә РФПСП күләме» сүзләрен «РФПСП дотацияләре күләме» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта тиешле килештәге «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен тиешле килештәге «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта тиешле килештәге «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен тиешле килештәге «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә алмаштырырга;

п) 13 пунктта:

беренче абзацта тиешле килештәге «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен тиешле килештәге «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта тиешле килештәге «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен тиешле килештәге «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «бюджет тәэмин ителешен» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителешен» сүзләренә алмаштырырга;

р) 14 пунктның беренче абзацында тиешле килештәге «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен тиешле килештәге «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә алмаштырырга, татарча текстта абзацның калган өлешләре үзгәрми;

с) 15 пунктта:

беренче абзацта ике җирдә «РФПСП акчаларының» сүзләрен «РФПСП дотацияләренең» сүзләренә, өч җирдә «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта ике җирдә «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә, «РФПСП акчаларының» сүзләрен «РФПСП дотацияләренең» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта ике җирдә «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә, «РФПСП акчаларын» сүзләрен «РФПСП дотацияләрен» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «акчалары өлеше» сүзләрен «дотацияләренең беренче өлеше» сүзләренә, «беренче этапта бүленгән» сүзләрен «, хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, авыл җирлекләре арасында бүленә торган» сүзләренә алмаштырырга;

т) 16 пунктта:

бишенче абзацта «бюджет тәэмин ителешен» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителешен»сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта ике җирдә «бюджет тәэмин ителеше» сүзләрен «хисаплы бюджет тәэмин ителеше» сүзләренә, «акчаларының» сүзен «дотацияләренең» сүзенә алмаштырырга;

у) 17 пунктның беренче абзацында «Авыл җирлегенең» сүзләрен «I-авыл җирлегенең» сүзләренә алмаштырырга;

ф) 18 пунктның беренче абзацында «шәһәр, авыл җирлекләренә дотацияләр» сүзләрен «шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр» сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

1. Әлеге Закон, 1 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 һәм 2 пунктлары 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 15 июле
№ 58-ТРЗ



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 682. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяда:

а) 1 өлештә:

18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым-аерым җыю) һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу;»;

20 пунктта «шул исәптән сатып алу юлы белән,» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 39 пункт өстәргә:

«39) «Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләрен башкаруда катнашу.»;

б) 3 өлештә:

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым-аерым җыю) һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу;»;

түбәндәге эчтәлекле 16 – 19 пунктлар өстәргә:

«16) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында җирлекләр чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

17) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

18) милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

19) җирлек халкының күпләп ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, моңа гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына теләгәндә керә алуын тәэмин итү дә керә.»;

в) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә шәһәр җирлекләре өчен каралган, әлеге статьяның 3 һәм 4 өлешләре нигезендә авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән җирле әһәмияттәге башка мәсьәләләр муниципаль районнарның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре булып тора һәм авыл җирлекләре территорияләрендә тиешле муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан хәл ителә.»;

2) 15[1] статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:

«14) җирлек территориясендә яши торган хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау чараларын күрергә.»;

3) 16 статьяның 1 өлешендә:

а) 14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14) тиешле муниципаль районнар территорияләрендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым-аерым җыю), ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнашу;»;

б) 15 пунктта «, шул исәптән сатып алу юлы белән дә» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 19[3] пункт өстәргә:

«19) муниципаль район милкендәге мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклап калу, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру, муниципаль район территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклау;»;



г) түбәндәге эчтәлекле 35 пункт өстәргә:

«35) «Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкаруны оештыру һәм территориянең карта-планын раслау.»;

4) 17 статьяның 1 өлешендә:

а) 24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым-аерым җыю), ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнашу;»;

б) 26 пунктта «, шул исәптән сатып алу юлы белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 43 пункт өстәргә:

«43) «Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкаруны оештыру һәм территориянең карта-планын раслау.»;

5) 17[1] статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле15 пункт өстәргә:

«17) шәһәр округы территориясендә яши торган хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау чараларын күрергә.»;

6) 18 статьяның 1 өлешендә:

а) 6[1] пунктка «программаларын» сүзеннән соң «, җирлекләрнең, шәһәр округларының транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын, җирлекләрнең, шәһәр округларының социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын» сүзләрен өстәргә;

б) 8[1] пунктка «, Россия Федерациясенең мәгариф турында законнарында һәм Россия Федерациясенең муниципаль хезмәт турында законнарында каралган тәртиптә муниципаль хезмәт өчен кадрлар әзерләүне оештыру» сүзләрен өстәргә;

7) 20 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 5[1] өлеш өстәргә:

«5[1]. Гражданнардан сорашып белешү үткәрүне билгеләү һәм уздыру муниципаль берәмлек уставы һәм (яисә) муниципаль берәмлек вәкиллекле органының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.»;

8) 21 статьяда:

а) 4 өлешнең өченче абзацына «, җирлек башлыгы хәлиткеч тавыш хокукы белән җирлекнең вәкиллекле органы составына керә һәм аның рәисе вәкаләтләрен башкара» сүзләрен өстәргә;
б) 8 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

9) 22 статьяның 10 өлешендә «урындагы зат» сүзләрен «вазыйфаи зат әлеге Законның 24 статьясындагы 4 өлеше нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

10) 23 статьяда:
а) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:
«$4^1$. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарын кабул иткәндә муниципаль берәмлек башлыгы тавышы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты тавышы буларак исәпкә алына.»;
б) 5 өлешнең икенче җөмләсендә «Җирле» сүзен «Әлеге Законның 24 статьясындагы 3 өлешенең 1 пункты яисә 4 өлеше нигезендә җирле» сүзләренә алмаштырырга»;

11) 24 статьяда:
а) 3 өлешнең 2 пунктында «муниципаль берәмлекнең» сүзләре алдыннан «хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән» сүзләрен өстәргә;
б) «Әлеге статьяның 3 өлешендәге 2 һәм 3 пунктларында билгеләнгән чикләүләр» сүзләрен «Әлеге статьяның 3 өлешендәге 3 пунктында билгеләнгән чикләүләр» сүзләренә алмаштырырга;
в) 6 өлешкә «әгәр муниципаль берәмлек башлыгы» сүзләреннән соң «әлеге статьяның 3 өлешендәге 1 пункты яисә 4 өлеше нигезендә» сүзләрен өстәргә;

12) 26 статьяның 1 өлешендәге икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Әлеге Законның 24 статьясындагы 3 өлешенең 1 пунктында һәм 4 өлешендә каралган очракларда муниципаль берәмлек башлыгы җирле администрация башлыгы булып тора. Башка очракларда җирле администрация башлыгы муниципаль берәмлек уставында билгеләнгән вәкаләтләр чорына җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча төзелә торган контракт буенча шушы вазыйфага билгеләнеп куелган зат була.».

13) 29 статьяда:
а) «Җирле үзидарә» сүзләрен «1. Җирле үзидарә» сүзләренә алмаштырырга;



б) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:
«2. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләре срогы муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнә һәм ике елдан кимрәк, биш елдан артыграк була алмый.»;

14) 33 статьяның 6 өлешендәге беренче абзацында «аларны акчалата тотуга факттагы чыгымнарын» сүзләрен «аларның хезмәте өчен түләүгә фактагы чыгымнарны» сүзләренә алмаштырырга;

15) 39 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«39 статья. **Шәһәр һәм авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләү**

Шәһәр һәм авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләү Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

16) 40 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«40 статья. **Муниципаль районнарның, шәһәр округларының бюджет тәэмин ителешен тигезләү**

Муниципаль районнарның, шәһәр округларының бюджет тәэмин ителешен тигезләү Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, аның 1 статьясындагы 1 пунктының «а» пунктчасындагы икенче һәм өченче абзацларыннан, «б» пунктчасыннан, 3 пунктындагы «а» һәм «в» пунктчаларыннан, 4 пунктындагы «а» пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «а» пунктчасындагы икенче һәм өченче абзацлары, «б» пунктчасы, 3 пунктындагы «а» һәм «в» пунктчалары, 4 пунктындагы «а» пунктчасы 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 21 июле
№ 59-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 683. «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8; 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 1 – 2, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяда:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Россия Федерациясе территориясендә даими һәм законлы нигезләрдә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының, башка затларның бергәләп дин тоту һәм дин тарату максатларында төзелгән һәм законда билгеләнгән тәртиптә юридик зат буларак теркәлгән иректе берләшмәсе дини оешма дип таныла.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $6^1$ пункт өстәргә:

«$6^1$. Гамәлгә куючыларның һәм башка юридик яисә физик затларның дини оешмалар эшчәнлегендә катнашу мәсьәләләре, дини оешма органнарын төзү тәртибе һәм аларның компетенциясе, шушы органнарның карарлар кабул итү тәртибе, шулай ук дини оешма һәм аның органнары составына керүче затлар арасында мөнәсәбәтләр дини оешмалар тарафыннан «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1997 елның 26 сентябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре нигезендә билгеләнә.»;

2) 11 статьяда түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5. Дини оешма төзү турындагы карарда дини оешманы төзү, аның уставын раслау, дини оешма органнарын сайлау (билгеләп кую) хакындагы белешмәләр күрсәтелә.»;



3) 19 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Дини оешмалар дәвалау-профилактика һәм хастаханә учреждениеләрендә, балалар йортларында, картлар һәм инвалидлар өчен интернат-йортларда андагы гражданнарның үтенече буенча бу максатларга администрация тарафыннан махсус бирелә торган урыннарда дини йолалар һәм тантаналар башкарырга хокуклы. Җинаять җәзасын үтәүче учреждениеләрдә дини йолалар, тантаналар һәм шәхси очрашулар Россия Федерациясенең җинаять-үтәтү законнары таләпләрен үтәгән килеш башкарыла.

Сак астында тоту урыннарындагы биналарда дини йолалар һәм тантаналар башкару Россия Федерациясенең җинаять-процессуаль законнары таләпләрен үтәгән килеш рөхсәт ителә.

Дини йолалар һәм тантаналар мәгариф оешмалары территорияләрендә урнашкан дини билгеләнештәге биналарда, корылмаларда да, шулай ук мәгариф оешмаларының дини йолалар башкару өчен элек-электән файдаланыла торган урыннарында үткәрелергә мөмкин.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 21 июле
№ 60-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 684. Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); Ватаным Татарстан, 2015, 7 июль) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның 3 өлешендәге 1 пунктында «югары һөнәри» сүзләрен «югары» сүзенә, «югары яисә» сүзләрен «югары белем яисә» сүзләренә алмаштырырга;

2) 13 статьяның 1 өлешендәге 7 пунктында «квалификациясен арттырырга» сүзләрен «өстәмә һөнәри белем алырга» сүзләренә алмаштырырга;

3) 15 статьяның 1 өлешендәге 4 пунктында «комачауларлык һәм» сүзләреннән соң «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон нигезендә» сүзләрен өстәргә;

4) 21 статьяның 4 өлешендә «квалификацияләрен күтәрергә» сүзләрен «өстәмә һөнәри белем алу өчен» сүзләренә алмаштырырга;

5) 30 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль хезмәт стажын исәпләп чыгару календарь тәртибендә башкарыла, мондый исәпләүгә гражданнарның чакырылыш буенча хәрби хезмәт узу вакыты керми, ул исә хәрби хезмәтнең бер көне өчен ике эш көне буларак исәпләнә. Муниципаль хезмәт стажын исәпләп чыгарганда хезмәт (эш) чорлары бергә кушыла.»;

6) түбәндәге эчтәлекле $34^1$ статья өстәргә:



«$34^1$ статья. **Муниципаль хезмәт өчен кадрларны шартнамә нигезендә әзерләү**

1. Муниципаль хезмәтнең югары квалификацияле кадрлар составын булдыру максатларында җирле үзидарә органнары, мәгариф турында Россия Федерациясе законнары нигезендә һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, муниципаль хезмәт өчен гражданнарны шартнамә нигезендә әзерләүне оештыра алалар.
2. Укып бетергәч муниципаль хезмәт узу йөкләмәсен алып максатчан уку турында шартнамә (алга таба – максатчан уку турында шартнамә) җирле үзидарә органы белән граждан арасында төзелә һәм уку тәмамланганнан соң гражданның күрсәтелгән җирле үзидарә органында билгеләнгән срок дәвамында муниципаль хезмәт узу буенча йөкләмә алуын күз алдында тота.
3. Максатчан уку турында шартнамә төзү конкурс нигезендә башкарыла.
4. Конкурс җирле үзидарә органы тарафыннан игълан ителә һәм җирле үзидарә органында төзелә торган конкурс комиссиясе тарафыннан үткәрелә.
5. Максатчан уку турында шартнамә төзүгә конкурс үткәрү турындагы мәгълүмат муниципаль хокукый актлар рәсми басылып чыга торган басма массакүләм мәгълүмат чарасында күрсәтелгән конкурсны үткәрү датасына кимендә бер ай кала басылып чыгарга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җирле үзидарә органының рәсми сайтына урнаштырылырга тиеш.
6. Әлеге статьяның 5 өлешендә каралган конкурс үткәрү турындагы мәгълүматта граждан уку тәмамланганнан соң биләп торырга тиешле муниципаль хезмәт вазыйфаларының төркемнәре; шул вазыйфаларга карата квалификация таләпләре; әлеге статьяның 8 өлеше нигезендә конкурска тапшырыла торган документларның исемлеге; аларны кабул итү урыны һәм вакыты; күрсәтелгән документлар кабул итүнең чик вакыты; конкурс үткәрү датасы, урыны һәм тәртибе күрсәтелә, шулай ук мәгълүмат бирүче башка материаллар күрсәтелгән булырга мөмкин.
7. Максатчан уку турында шартнамә төзүгә конкурста Россия Федерациясе дәүләт телен белгән һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчалары исәбеннән беренче тапкыр урта һөнәри һәм югары белемне көндезге уку рәвешендә алучы гражданнар катнашырга хокуклы. Күрсәтелгән конкурста катнашучы граждан муниципаль хезмәткә кергәндә, шулай ук әлеге статьяның 14 өлешендә каралган бөтен срок дәвамында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон белән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләп тору өчен каралган таләпләргә туры килергә тиеш.

8. Конкурста катнашырга теләк белдергән граждан җирле үзидарә органына түбәндәгеләрне тапшыра:

1) шәхси гаризаны;

2) муниципаль хезмәткә керә торган граждан тарафыннан җирле үзидарә органына тапшыру өчен федераль законнар нигезендә расланган форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкетаны, аңа фоторәсем кушып бирелә;

3) паспорт күчермәсен (паспорт конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә);

4) хезмәт кенәгәсенең күчермәсен яисә гражданның хезмәт эшчәнлеген раслый торган башка документларны (хезмәт эшчәнлеге элек башкарылмаган очраклардан тыш);

5) гражданның «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон нигезендә муниципаль хезмәткә керүенә һәм аны узуына каршы килә торган авыруы булмау хакында медицина оешмасы бәяләмәсен;

6) гражданның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджеты акчалары исәбеннән беренче тапкыр урта һөнәри яисә югары белемне көндезге уку рәвешендә алуын раслый торган, шулай ук ул үзләштерә торган уку-укыту программасы турында (һөнәрнең, белгечлекнең исемен яисә әзерлек юнәлешен күрсәтеп), уку планы нигезендә гражданның урта аттестация узу нәтиҗәләре хакында, мәгариф оешмасының уставында һәм эчке тәртип кагыйдәләрендә каралган йөкләмәләрнең аның тарафыннан үтәлүе турында мәгълүматны үз эченә алган мәгариф оешмасы белешмәсен.

9. Персональ мәгълүматларның һәм әлеге статьяның 8 өлеше нигезендә граждан тарафыннан тапшырылган документларга кертелгән башка белешмәләрнең дөреслеге һәм тулылыгы җирле үзидарә органы җитәкчесе карары буенча тикшерелергә мөмкин.

10. Конкурс комиссиясе дәгъва итүчеләргә әлеге статьяның 8 өлешендә күрсәтелгән тапшырылган документларга нигезләнеп, шулай ук конкурс процедуралары нәтиҗәләре буенча бәя бирә. Конкурс процедураларына әңгәмә, анкета тутыру, тест эшләү, язма биремнәр эшләү һәм федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм башка норматив хокукый актларга каршы килми торган башка процедуралар җирле үзидарә органы карары буенча кертелергә мөмкин.

11. Конкурс комиссиясе муниципаль хезмәт вазыйфасын биләп торуга конкурс үткәрү өчен муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы муниципаль хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә утырышлар үткәрә һәм максатчан уку турында шартнамә төзү хакында карар кабул итә.



12. Конкурста катнашкан гражданнарга конкурс тәмамланган көннән соң бер ай эчендә язма рәвештә нәтиҗәләр турында хәбәр ителә.

13. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс үткәрү урынына транспортта бару һәм кире кайту, торак урынын наемга алу, яшәү, элемтә чаралары хезмәт күрсәтүләреннән файдалану һәм башкалар) гражданнарның үз акчалары исәбеннән тотыла.

14. Максатчан уку тәмамланганнан соң муниципаль хезмәтне мәҗбүри узу срогы максатчан уку турындагы шартнамәдә билгеләнә. Күрсәтелгән срок максатчан уку турында шартнамә нигезендә гражданга җирле үзидарә органы тарафыннан социаль ярдәм чаралары күрсәтелгән сроктан ким була алмый, әмма ул биш елдан күбрәк булырга тиеш түгел.

15. Максатчан уку турында шартнамә якларының йөкләмәләре һәм җаваплылыгы максатчан уку турында шартнамәдә Россия Федерациясе законнарына туры китереп билгеләнә.

16. Максатчан уку турында шартнамә граждан белән бер генә тапкыр төзелә ала.

17. Максатчан уку турында шартнамәдә каралган чыгымнарны финанс белән тәэмин итү җирле бюджет акчалары исәбеннән башкарыла.»;

7) 38 статьяның 3 пунктында «муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү» сүзләрен «муниципаль хезмәт өчен кадрлар әзерләү һәм муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә һөнәри белем бирү» сүзләренә алмаштырырга;

8) 4 нче кушымтада:

а) 18 пунктның 3 пунктчасында «квалификация күтәрү» сүзләрен «өстәмә һөнәри белемне уңышлы алу» сүзләренә алмаштырырга;

б) 21 пунктның 2 пунктчасында «квалификация күтәрүгә» сүзләрен «өстәмә һөнәри белем алу өчен» сүзләренә алмаштырырга;

в) 22 пунктта «квалификация күтәрүдән» сүзләрен «өстәмә һөнәри белем алудан» сүзләренә алмаштырырга;

г) Муниципаль хезмәткәрләргә аттестация үткәрү турында үрнәк нигезләмәгә кушымтаның 10 пунктында «квалификация күтәрү» сүзләрен «өстәмә һөнәри белемне уңышлы алу» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 21 июле
№ 61-ТРЗ